Ренат Харрис
Исемсезләр

Шигырь роман

Казан
Татарстан
китап нәшрияты
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-6
Х32

**Харисов Ренат**

Исемсезләр: Шигырь роман. Фоат Галимуллин кереш сүзе.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 191 б.

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харисның бу әсәрендә чорыбызның гыйбрәтле вакыйгалары, замандашларыбызның кабатланмас мәхәббәт язмышлары, илдә барган болганчык һәм катлаулы күчешләр дәверенең гомерләргә тигән җиле үзенчәлекле сурәтләү чаралары аша бәян ителә.

ISBN 5-298-01454-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## Затлы традицияләр дәвамы

Бу китап, кайсы гына яктан алып карасаң да, гадәти генә бер күренеш түгел. Ул татар әдәбиятының күп гасырлардан килгән затлы традицияләренең дәвамы буларак кабул ителә. Иң әүвәл аның жанры игътибарны җәлеп итә — шигъри роман. Татар әдәбиятында бу олы жанрның барлыкка килүе очраклылык түгел иде. Аның юл башында үзе дә романнарга тиң «Кыйсса-и-Йосыф» тора. Ундүртенче гасырның беренче яртысында Котбның «Хөсрәү вә Ширин» исемле шигъри романы бу үсешнең табигый сыйфат сикереше иде. Димәк, бездә шигырь белән роман язу моннан алты йөз ел элек башланган икән. Бу яктан күп кенә халыклар безгә көнләшеп карыйлар. Соңгы гасырда гына да С.Баттал, Ш.Мөдәррис, Ш.Маннурлар моның матур үрнәкләрен бирделәр.

Яңа — XXI гасыр башында бу олы жанрны Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис тергезеп җибәрде. Болай диюнең сәбәбе бар. Хәзер компьютер, интернет заманы, кешенең калын-калын китаплар укырга вакыты юк, дип, әдәби әсәрләр иҗат итүдә кыскалыкка өстенлек бирү күзәтелә башлады. Хәтта кырык битле проза әсәрен дә роман дип атау белән очрашырга туры килә. Шулай да роман роман булсын өчен, күләмнән бигрәк, әсәрнең сюжет оештырылышы рәвеше беренчел шарт булып тора. «Исемсезләр» әсәре — моның отышлы мисалы.

Иҗат кешесе буларак, авторның кыюлыгы һәм колачлылыгы шунда: ул шактый җыйнак бер мәйданда егерменче гасырның иҗтимагый-сәяси шартларындагы кешенең хәлен ихласлык, сәнгатьчә дәреслек белән сурәтләүне максат иткән. Моны ул шактый саран, әмма үтемле образлылык чаралары ярдәмендә тормышка ашырган. Исемсез геройлар исә сурәтләнгәннәрнең зур гомумиләштерү хасиятен булдыру мөмкинлеген тудыралар. Исемсезләр артында меңнәрчә-меңнәрчә исемнәр торуын аңлау узган гасырдагы хәл-әхвәлләр белән азмы-күпме таныш кешеләргә кыенлык тудырмый. Яңа буын укучылары өчен дә биредә бәян ителгәннәр гыйбрәтле булачак.

Безнең халыкта бер Генераль Секретарь үлсә (чөнки алар бу урыннан исән килеш китмиләр иде), икенчесе илдә тәртип урнаштырмасмы, дигән ышаныч яшәде. Әмма сиксәненче елларда илнең әлеге иң олы җитәкчеләре бер-берсен алыштыра тордылар, тик берни дә үзгәрмәде. Чынга ашмаган өметләр әкренләп сүнә торды, ил төшенкелеккә бирелде. Мондый хәл бик күпләрнең язмышы аянычлы юлдан китүенә сәбәп булды. Шагыйрь йөрәк әрнеше белән шуларны бәян итә.

Ренат Харис — XXI гасыр башы татар шигъриятенең иң исемле шагыйрьләреннән берсе. Бу

әсәре аның шигъри куәтен яңа көч белән янә раслады.

*Фоат Галимуллин,*
*профессор,*
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе.*
*9 октябрь, 2004*

«Ищу героя! Нынче что ни год
Являются герои, как ни странно...
...Сезон прошел – герой уже не тот...»

*Дж. Байрон. «Дон Жуан»*

«Как он умел казаться новым...»

*А. Пушкин. «Евгений Онегин»*

«Герой Нашего Времени, милостивые государи мои, точно, портрет, но не одного человека: этот портрет, составленный из пороков всего нашего поколения, в полном их развитии

*М.Лермонтов. «Герой нашего времени»*

«Үзебезне үзәк санап,
Без телибез яшәргә.
– Кысылыгыз! – дип, картларга,
– Кысмагыз! – дип, яшьләргә...»

*С.Баттал. «Чирмешән якларында»*

**1**

Герой эзлим! Герой эзлим
күз бетереп, җир ертып —
әйтерсең лә татарда мин
Байрон, Пушкин, Лермонтов!..
Әлбәттә, татарны эзлим,
Шуңа эзлим татардан —
таба алсам, яза алсам,
татарга да булыр дан...
Дон Жуан да, Онегин да,
Рахметов һәм Печорин
үзләренә сыйдырган ич
үз кавемен, үз чорын!
Әллә бездә юк дисезме?
Булырга тиеш — күрсәң,
һәр күренекле татарның
иңенә кунып йөрсәң,
яхшысын да, яманын да
теркәүче фәрештә күк...
Ләкин алай йөреп булмый —
парламентта эшләр күп:
законнарның без федераль
кыршаудан чыкканнарын
янә тәңгәлләштерәбез,
күз күрер, дип, аннары...

...Эзлим аннан, эзлим моннан...
Таба алмый тик торам —
кило белән үлчисене

үлчим, ахры, метрлап.
Бәлки, литрлап кирәктер?!
Акыл ич бу, күр әле!
Безнең Россиядә литр —
универсаль берәмлек.
Үлчәм дә ул, акча да ул,
ул керү билеты да
йөрәккә, склад-мазарга,
түрә кабинетына...
Минутны, ваттны, амперны,
байтны һәм градусны
бездә литр алмаштыра!
Бар дөнья белә бусын...

Шактый, шактый еллар элек —
Брежнев чоры иде —
язмыш буйлап йөрткән юллар
коры һәм туры иде.
Абыныйм дигән кешегә
мөмкинлекләр күп иде —
шактый кеше литр дигән
тайгалакта гөп итте...
Мин Мәскәүгә барган идем,
вак-төяк бер эш белән.
Андый командировкалар
була иде еш кына,
чөнки башкала ул чакта
үрмәкүч кебек иде —
пәрәвезенең җепләрен
илдә һәр кеше тойды.
Мәскәү рөхсәтеннән башка
чебен дә очмый иде.
Башкаланың кулы озын,
ә күзе очлы иде.
Кибетләргә дә бай иде
сөекле башкалабыз...
Казан колбасаларын да
анда барып алабыз.
Ә «Березка» кибетләре! —
хәзинә кабы! Якты!
Чиста! Матур! Анда безнең
селәгәй күпме акты!
Кыштырдадылар рубльләр
кесә төбендә генә,
чөнки «Березка»да товар
фәкать тегендәгегә —
долларга, фунтка, маркага...
Бездә андый валюта
кесәдән түгел телдән дә
алынган иде утап.
Ә кафелар! Рестораннар!
Кызыл, кара уылдык!..
Коньяк!.. Кыскасы, башкала
оҗмах булып тоелды.
Шул оҗмахка керергә дә
җитте ул чак эш хакы...
Менә нинди торгынлыкта
без яшәп, череп яттык!..
Барырга җай чыккан саен
бара да кайта идек —

кичен батып, иртән калкып
шомарган кояш кебек...
Мәскәүнең киң урамнары
бик еш кына тар иде —
шуңа күрә көтелмәгән
очрашулар бар иде,
чөнки барлык мәсьәләләр
хәл ителде биредә:
уңае, шиксез, уңайга,
ә киресе — кирегә.
Киресенчә дә күп булды.
Чәкчәк, Васильевоның
утка түзәр пыяласы,
бүрек, цигейка туны,
тауны Мөхәммәт катына,
ә елгаларны үргә
юнәлттеләр ипләп кенә,
җигелеп тартып бергә...
Ул чакларда андый көчләр
«күчтәнәч» һәм «сувенир»
диеп аталалар иде...
Бүген бары сүгенер
мондый гына «күчтәнәч»кә
хәтта заштатный түрә,
чөнки түрә «яшелкәйне»
чәкчәктән артык күрә...

Шул баруда очраттым мин
Ташкенттагы абзамны —
башкача ничек аңлатыйм —
Ходай шулай язгандыр.
Абзам Ташкент метросының
яктыртылу челтәре
проектын ясаган да
монда килгән күтәреп.
«Москва» кунакханәсенең
җиденче катындагы
ресторанында утырдык,
ике буш урын табып.
Тагын бер урын буш иде.
Ә менә дүртенчесе
буш түгел, ләкин каядыр
киткән иде кешесе.
Төрле итләр, яшелчәләр,
гөмбә, зәйтүн җимеше,
балык... Ахры, бик тә важный
иде билгесез кеше.
«Очрашу хөрмәтенә!» — дип,
рюмкалар чәкешкәндә,
күршебез дә пәйда булды
шактый күңелле хәлдә.
Безнең шешәдән үзенә
койды да ул тиз генә,
чәкеште, сүзләрен ялгап
минем абзый сүзенә:
— Якташлар, татарлар икән...
Табын минем хисапка...
...Безгә өстәргә кереште:
— Ярый күбрәк койсак та...
Официантка! Бирегә!

Өстәмә ике шешә!..
...Официантка кырт кисте:
— Ярамый чит кешегә,
чөнки алай килешмәдек...
Үз шешәгез бетмәгән,
кабымлыклар да җитәрлек...
Калачаклар түкмәгә...
— Не грубите! Мин — җиңүче!
Теләсә ни дисәң дә...
— Мин китерәм — кыен түгел...
акча — синең кесәңнән...

...Күршебез аңлатып бирде
без аңламаган сүзне:
кичә ул шушы өстәлдә
өч сәгатьтә берүзе
өч «ярты» эчеп бетергән
һәм, чайкалмыйча бер дә,
рестораннан чыгып киткән
әкияттәге ирдәй.
Әлбәттә, пари тотканнар:
шартларын бу үтәсә,
официанткалар аны
җаны теләгән нәрсә
белән үз исәпләренә
сыйларга тиеш бүген;
бу җиңгән һәм табын аңа
паридагыча — тиген...
Без килгәнче, бер шешәне
ул йотып куйган икән,
айгыры кешни башлаган,
сәхрәгә чыгып киткән.
Бию мәйданы янында
өч хатын... Шундый чибәр.
Чиратлап бии... «Без сине
читкә бирмибез»,— диләр.
Нефтьче икәнлеген дә
белеп алгач, тәтәйләр
биегәндә аның белән
әллә ниләр нитәләр.
Өчесе дә бер үзенә
нәфселәрен сузалар,
хәтта аның номерына
барырга да ризалар...
Күрше безне шул тәтәйләр
белән таныштырмакчы —
савап булган кичәбезне
гөнаһ юлга бормакчы.
Без, әлбәттә, баш тартабыз,
нервылы сулый-сулый —
мондый кыю әхлаксызлык
безнең акылга сыймый —
абзый-эне арасында
итагать бар ич бездә:
аерым-яшьрен әллә нишлә,
тик капма күмәк күзгә,
туганнарыңа белгертмә,
чөнки алар фикере —
абруйдагы иң биек тау...
Үтеп булмый сикереп.

Татар була торып, күрше
югалткан шул тоемын,
күрәсең, бик күп эчкәндер
суын башка коеның...

Нефтьче-тәэминатчыны
калдырып торыйк әле...
Абзыйдан Ташкент хәлләрен
төпченик-сорыйк әле.
Нефтьче, үзе әйтмешли,
сәхрәләр кичә торсын.
Акчасы аның җитәрлек —
реаль хыяллар корсын,
шуны тормышка ашырсын,
тик бәлагә тармасын.
Шәһәрдә бик еш көпчәксез
кала авыл арбасы!..
«Казан бальшуй, ә Маскыва
бик маленький!» дисәк тә,
башкалада хәйлә, мәкер
чын мировой исәптә!..
Хәтта Казандагыдан да
бераз гына артыктыр.
Ләкин Казан шул көчләрен
чыгара тик саркытып...
Казан евро-азиялек
мәркәзенә әйләнде —
Европадан — яшеренлек,
Азиядән — хәйләлек...
Ә Мәскәүдә ни генә юк!
Мәскәү — гаҗәеп шәһәр:
фахишәлек, әлбәттә, юк,
ләкин бар фахишәләр.
Аларның профсоюзы
юк, әлбәттә... Ә челтәр...
сайлап кына ышанычлы
күңел тәрәзен чиртә,
һәм теге тәрәз ачыла,
онытыла дәрәҗә,
партбилет та онытыла —
кәбестә күрде кәҗә!

Ташкент хәлләре дигәндә...
— Әйтсәк өч-дүрт сүз белән:
күршеләр белән ярышып,
шәһәр гөрләп төзелә;
метро станцияләре
затлы ташлардан тора —
без бит сезнең кебек түгел,
тормыйбыз рөхсәт сорап;
о, күрсәң Ленин музеен!
Төсле каскад-фонтанны!
Ташкентны СССРдагы
иң шәп кала дип саныйм.

Яңа танышыбыз бию
мәйданы уртасында
чак кыймылдый... Инде үзе
тәтәйгә асылынган.
Ләкин кулы шуып төшә

шактый текә бөердән...
Авыр башын артка ташлап,
борнын күккә чөергән,
чөнки зур эшләр башкарган:
Түмәнгә йә Бакыга
дигән нефть җиһазлары
кайта безгә! Вакыйга
чиктән тыш әһәмиятле,
кирәк моны аңларга!
Шуның өчен ни кыланса,
шул килешә аңарга.
Карсак буйлы,киң җилкәле,
авыр башлы бу иргә
Ходай нинди чыдам йөрәк
һәм таза бәдән биргән!
Нефтьчеләр өстәгәннәр
чиксез мөмкинчелекләр:
кирәк булса, йөз кешене
сатып ала, эчерә,
нефть алуны арттырып
илне баету өчен,
кызганмый сәламәтлеген,
горурлыгын һәм көчен.
Хәтәр хәлләр ташкынына
ыргыла тәвәккәлләп —
яшәсен генә нефтьче
һәм чәчәк атсын Әлмәт!..
Ә партия тота аны
шактый кырыс йөгәндә —
үз мәнфәгате хакына,
кызыгып, күз көйгәндә,
ул начальникларга карый —
аларны уздырмыймы?!
Иерархия тәртибен
азынып туздырмыймы?
Партвзносын эш хакыннан
түли... Ләкин кайчакта
намусы белән кесәсе
килә пычак-пычакка.
Һәм яралана намусы!..
Яраны кысып, поса...
Нишлисең бит, бездә кесә
көчлерәк шул намустан...
Ләкин намуссызлык түгел
аның мондый адымы —
ул партия уставының
чын хезмәтче-хадиме.

Мин эзли торган геройның
бу, бәлки, нәкъ үзедер?!
Ләкин бик мактамыйк әле —
әллә нишләр, күзегер,
әнә бит нинди хатыннар
аны алганнар урап!..
Еланнарга карышучы
куян күк басып тора.
Карышу көче төкәнсә?
Йотсалар? Төкерсәләр?
Кесәсенә генә түгел,
тормышына керсәләр,

публичный скандал булып,
уголовный эш булып?
Тез аслары шактый йомшак,
аңында инде болыт,
колагы телен ишетми,
теле инде сер тотмас —
зур бәлага таруы бар,
катышмыйча да булмас...

Юк, катышмыйк! Безсез генә
яшәсен ул кешечә.
Яхшылык диеп тотынган
яманга чыкты ничә...
Көтик әле, бәлки, юллар
кисешерләр тагын да,
бәлки, исем дә кушарбыз
без аңа шул чагында,
әлбәттә, герой булырлык
кеше булып калса ул,
литр басымына чумып,
җан бирмәсә, кан савып...

**2**

Абзый шигырь яза иде...
Бик шәп түгел, өчлегә...
Ана телендә язмаучы
чын мәгънәдә көчлеләр
кайсы әдәбиятта күп?
Очрыйлар... Ләкин сирәк...
Тел һәм күңел икесе бер,
шуны аңларга кирәк.
Күңелдәге иң нечкә хис
бердәнбер сүзен тапсын,
шул сүз тормоз-тоткарлыксыз
килеп телеңә ятсын,
ә телең аны уйнатсын
шәп эквилибрист сыман:
күккә чөеп йолдыз итсен,
һавага өреп — томан,
суга салып дулкын итсен,
утларга ташлап — очкын,
ә очкын, мәхәббәт нуры
булып, дөньяны кочсын,
кагылсын һәрбер керфеккә,
күзләргә балкыш өстәп,
һәм балкыш кабат әйләнсен
күңелдә яңа хискә,
ул хис тә тапсын бердәнбер
үзенә лаек сүзен,
ул сүз дә безнең йөрәккә
өстәсен җылы эзен,
ә эз буйлап җаныбызга
яңа уй-хисләр керсен —
яхшылыкларны үстерсен,
яманлыкны үтерсен...
Ә бит шагыйрь булып була,
иң-иң-иң ким дигәндә,
Телең — Ана, үзең — Бала
булып сөтен имгәндә!

...Рус телендә яза иде...
Татарчамы? Русчамы?
Ансын төгәл әйтә алмыйм —
Билгесез иде җаны,
бикле иде минем өчен.
Аралар ерак иде,
шуңа күрә очрашулар
очраклы, сирәк иде...
Рус телендә дә татарча
язган язучылар бар...
Әйтик, Зөфәр Фәтхетдинов,
Равил Бохараевлар,
Роман Солнцев, Мир-Хәйдәров,
Михаил Львов абый,
Рөстәм Кутуй,Кашшафетдин...
Эзләсәң, була табып...
Шулай буламы соң, димсез?
Ничек аңлатыйм моны?..
Әйтик, Шаляпин җырында
булгандай татар моңы!
Татар телле маңкортлар бар,
башка телле асыллар —
тел ул сүздә генә түгел,
тел ул — җан кыйбласында!

Аяклы әбрәкәй сыман
«хуш исле» шагыйребез
бу темага бер гәзиттә
әйткән шактый өре сүз:
«Татарда урысча уйлап,
татар сүзләре белән
шигырь язулар күбәйде —
яман ис шуннан килә
татар әдәбиятына,
җәберләп милли хисне...»
Йа Ходa, аракы исе
әбрәкәй исен сизми...
Наданлык җиле һәрвакыт
көнләшә фән җиленнән.
Кайсы җилләр күбрәк икән
бүген туган илемдә?!

Абзыйның бөтен язганы
гәзитләрдән узмады —
журналлар кире какканнар,
китап та юк... Кызганыч,
үзгәртеп кору чорыннан
файдалана алмады.
Бүген китап чыгармаган
бер графоман да калмады.
Ул да, спонсорлар табып,
Томнар чыгарыр иде...
Аның өчен чор соңгарды,
Газраил иртә килде...

Мәскәүдә язучыларның
бар икән ресторaны.
Абзый, монда килгән саен,
бернигә дә карамый,
шунда бара, чөнки үзен

анда бәхетле сизә —
башкала богемасында
ЦДЛ — иң шәп үзәк!
Кемнәр генә булмый анда!..
Замана даһилары!
Һәркайсын значок итеп,
лацканга таксаң ярый!
Ишетүгә караганда,
хәерле барып күрү...
Кичке уннар тирәсендә
без шунда барып кердек...
«Война и мир» геройлары
биеп йөргән залларда
тәмәке төтене исе...
Монда узган баллардан
хәбәрдар сынлы баскычлар,
колонна, имән бизәк
спиртлы төтен исеннән
каралмый ничек түзгән!..

Витражлы готик тәрәзә
һәм янып торган камин!
Аларны әллә кинодан,
әллә китаптан таныйм.
Кыскасы, күзгә кергәннәр
күңелне алды үбеп,
ач карынга йотып куйган
җылынган «Кагор» кебек —
әйләнеп китте башларым,
йөрәккә канат иңде...
Күзем Сергей Михалковны,
Гамзатны эзли инде,
Мостайны, Евтушенконы
күрәсе килә үлеп...
Ләкин урын табасы бар
барысыннан да элек...
Мин күзәтәм... Барлык хатын
Белла Ахмадуллина
йә Юлия Друнина
булып күренә миңа...
Ниһаять, урын да булды
шактый тыгыз өстәлдә.
Берсе буш иде — абзыйга.
Миңа куйдык өстәмә.
Абзый танышып та алды —
җен төкергән теленә:
— Без — мәңге яшел чинарлар,
йөзем, кавын иленнән —
кояшлы Үзбәкстаннан,
Ташкент дигән каладан.
Ташкентның хәтта ташларын
алтын кояш ялаган!..

Өстәлдәшләр аңа каршы
һич куймадылар кимен:
— Вологдадан — мәңге яшел
кыяр, помидор иле!
Китте көлеш һәм әңгәмә...
Тостлар түшәмгә тиде...
Абзам минем матур иде!

Абзам бәхетле иде!
Әкрен-әкрен өстәлдәшләр
өстәлделәр, киттеләр —
өзлексез һәм сиздермичә
алмашынып беттеләр.
Аңладым — тәрҗемәчеләр
иде безнең тирәдә...
Абзый алар тарафына
мондый фикер тибәрә:
— Чит телләрдән ят телләргә
тәрҗемәне хупламыйм;
ул, әлбәттә, шома була,
тик булмый кайнар каны,
калмый анда йөзем тәме,
калмый пылау хушисе...

Өстәлдәшләр тынып калды...
Берсенең китте төсе,
кабызды ул сигарасын,
өстәлгә төтен өрде...
Уч белән төтенне җилпеп,
абзый шактый йөткерде.
Төтенен кабат өрде дә
абзыйның борынына,
әйтте:
— Майлы куллар белән
Европага орынма,
син, азиат, әүвәл өйрән
тотарга агач кашык...

Шушы сүзне ишетте дә
абзый китте бит шашып:
— Тукта, безнең гадәтләрдән,
культурабыздан көлмә —
куллары шакшы кешеләр
ашаган кашык белән...

Табында тынлык урнашты,
салкын һәм авыр тынлык,
әйтерсең йөрәк эчендә
бер клапан ертылды.
Һич көтмәгәндә табынга
егылды бәла-каза...
— Беләсезме, мин бит — татар,
ә рус телендә язам...
Үзем сизәм — язганнарым
өченче телдә кебек:
шигырьдәге иреннәрне
карыйсы килми үбеп...

Яраны ялгыйм диеп, ул
яңа тоз гына салды...
Ике минуттан өстәлдә
без икәү генә калдык...
Кыен булды... Тик үкенмим —
ачтым абзыйның җанын.
Җаныннан минем йөрәккә
тулды фаҗига чаңы...
Канда — татар, телдә — урыс,
ә тәрбиядә — үзбәк...

Вакыт үткәрмик бу хәлнең
сәбәбен-ниен эзләп...

Абзыйның җанын аңладым —
риялы түгел иде,
горур очышта яшәгән
самими күңел иде.
Өч тарафка тартылуын
авыр кичерә иде,
аракыдан аек булды,
җырдан исерә иде —
үзе татарча җырламый,
оеп тыңлый, тулыша,
түзә, түзә, түзә, түзә —
еламаска тырыша,
аннары хисләр иркенә
ыргыта җан тышавын:
елый, елый, елый, елый —
тынычланып, бушанып
кала абзый, күзләренә
бәреп чыга оялу...
Нидер уйлап, уйны буйлап,
авыр сулап куя ул.

Яшерен дары тормышта
бар иде, коры иде...
Кайчак тешләр чакмасыннан
чәчрәгән очкын җитте
берәр шартлау чыгарырга
милли аң фронтында...
Тик канга сеңгән куркуның
кисәтүләрен тыңлау
тышка-җәмгыятькә түгел,
эчкә-йөрәккә таба
юнәлтә иде шартлауны,
һәм шунда бикләп яба...

Менә шулай тәмамланды
көтелмәгән очрашу.
Көтелмәгән очрашу ул —
көтелмәгән юл башы...
Көтелгәне генә булса,
кызык та булмас иде...
Менә минем романга да
азык табылмас иде.
Нәрсә язган булыр идем
тик ятсам номерымда?!
Күрәсез — романга герой
табылыр кебек монда...

**3**

Халыкка, илгә мәхәббәт
изгелек белән тулы.
Мондый мәхәббәттән генә
повесть, романнар тумый.
Җенси мәхәббәтләр кирәк!
Гөнаһлысы! Изгесе!
Мәхәббәт — ул кешедәге
кешелеклек көзгесе.
Һәм шул көзгедә чагыла

кешенең сыйфатлары —
сынап газапланасы юк,
гомер юлын актарып,
биреп түрә креслосы,
бурычка акча сорап...
Сөюенә генә кара —
җаны күренеп тора.
Монда да булыр мәхәббәт,
сабыр итик чак кына,
чөнки абзам кыен хәлдә,
абзам юллар чатында...

Ул бик күптәннән Казанга
күчәргә план корды,
ләкин юлында вак-төяк
киртәләр чыга торды:
менә фатир була, менә
командировка читкә,
менә тиздән җитәкчесе
олырак эшкә китә —
ачыла перспектива
тормышта да, фәндә дә...
Алтын чыңы ишетелә
кайчак бакыр тәңкәдән...
Йә хатыны, йә малае,
йә вакыты, йә эше...
Кыскасы, үз өметенә
абына кайчак кеше!..
Кыскасы, матур хыял да
тышау була икән ич.
Шул арада аның улы
тәмам үсеп җиткән ич —
мәктәпне дә тәмамлаган!
Исәп — институтка!..
Абзый шунда уйга талган
бик озын бер минутка...
Мәскәүдәге кичәдән соң
хәлләр булган абзыйда!—
язмышына тыкшынганнар
төрле-төрле казыйлар.

Үз дәрәҗәсен белепме,
язган псевдоним куеп...
Милләтче бер язучыны
эзләп өч-дүрт ай буе,
абзыйга килеп чыкканнар —
ул эшләгән НИИга...
Башкаладан ни чәпесәң,
изгегә дә шул йога!
ЦДЛда сәрхуш килеш
буза кубарган өчен,
үзбәктән тыш милләтләргә
пычрак атканга эчеп,
партиядән чыгарганнар,
түбәнәйткәннәр эштә...
Абзый нәҗестә таелган
матур атлап килештә...
Афәт аны, арттан җитеп,
бәреп еккан аяктан,
чөнки килгән ул беркем дә

чамаламаган яктан...
Бер тезгә төшеп көрәшкән
яралы Идегәйдәй —
горурлык аңа дәрт биргән,
ә ачу торган әйдәп.
Ләкин яуланган үрләре
кайтмаган инде кире...
Һәм Ташкент — минем абзыйның
туган һәм үскән җире —
табанын түгел, йөрәген
көйдереп торган ташка
әверелгән аның өчен,
һәм суынмаган башка...
Әнә шул озын минутта,
йөрәккә куеп кулын,
карарга килә: Казанга
юл ярсын әүвәл улым,
аннары аның артыннан
озак тормабыз без дә...

Һәм улы студент булды
Казанда нәкъ шул көздә.
Берничә ай бездә торды,
аннары тулай торак
алырга булыштым аңа,
ректорга кереп сорап.
Әгәр кермәгән булсам да
бирерләр иде... Ләкин
абзый алдында яхшатлы
буласы килде — әйтим.
Авыр чаклары иде бит.
Таяныч кирәк чагы!
Туганчыллыгым ташудан
куанып йөрдем чабып.

Егете дә әйбәт иде...
Аның төгәл сурәтен
күз алдыгызга куярга
телне ничек өйрәтим?!
Бер мәзәк кенә сөйлимче —
сөйләшә, ди, өч хатын:
икесе бик күтәрмәкче
улларының сан-атын.
Берсе әйтә: «Минем улым
яши китереп шартын,
хуш киләсез, хәзрәт! диеп,
каршылый яше-карты».
Икенчесе дә калышмый:
«Менә ул бу рәсемдә,
мөфти хәзрәт, нишлик? диеп,
йөриләр тирәсендә...»
Өченчесе: «Ә минекен
кызлар камап алалар,
сокланудан «Йа Ходай!» дип,
тынсыз-өнсез калалар...»

Мин дә өченчесе сүзен
кабатлаудан һич узмам...
Егет урамнан үткәндә,
борылып карый кызлар.

Акылда да тәңгәл иде
буй-сынына, төсенә,
телгә дә бик беткән иде
бар сыйфаты өстенә.
Урысчасы — урыс кебек,
үзбәкчәсе — чамалы,
татарчасы — өч-дүрт сүзгә
бер урысча җамаулы,
татар министры кебек,
йә бер район башлыгы...
Әмма ләкин егетне без
гаепләмик ашыгып —
ул бит татар авылында
тумаган, укымаган.
Тегеләр бит үскәч кенә
эләккәннәр калага.
Телгә беткәнлек — фикерне
матур әйтү сәнгате.
Сокландыра иде егет,
фикерен төгәл әйтеп.

Ярар, без аны беразга
калдырып торыйк әле,
хикәябезнең агышын
чак кына борыйк әле,
аның әтисенә таба...
Егет китсен колхозга —
студентның сентябре
бездә колхозда уза:
ашлык, яшелчә уңышы
мулмы, әллә сыекмы!
Без өйрәнгән кәкре сугып
бөкрәйтергә кыекны...

**4**

Абзыйдан хат килеп төште...
Роман хатсыз буламы?!
Әнә Пушкин ничек откан,
романда хат кулланып.
Анна Снегина хатын
үлгәндә дә ятларлык...
Ә Такташның киләчәккә
барып җиткән хатлары!
Гадел Кутуйның повесте
хатлардан гына тора.
Хатта тел түгел, җан сөйли,
ә җан телдән турырак...
Дөрес, кайберәүләр әйтә:
җанының нәкәслеген
яшерергә тел бирелә...
Бусы — шайтан кәсебе.

Шулай итеп, язган хатын
укый башлыйк абзамның...
Онытмагансыз дип уйлыйм
аның шигырь язганын.

«Сәлам Ташкент каласыннан,
бер татар баласыннан!

Сезне сагыну утында
миннән көл кала сыман.
Теге хәлләрне беләсез...
Аякка инде бастым...
Ләкин тотрыклы түгел шул
без баскан аяк асты.
Узган тарих тузаннарын
актаралар... Тарала...
Тәрәзәләрендә нурлар
безнең өчен карала...
«Остазымыз, рәхмәт!» — диеп
әйтәләр иде элек.
Үзләре хәзер кисаплар,
үзләре хәзер киле...
Без дә, безнең ишеләр дә
бары урынбасарлар.
Алга карап нәтиҗә дә
була инде ясарга...
Ләкин бу — туган җирем бит —
кендек канымны йоткан...
Җир тамыры, эчкә үтеп,
йөрәкне учлап тоткан.
Әти, әни кабередер
җир тамыры дигәнем.
Үзем дә сизмичә калдым
шул тамырга тигәнне...
Кичә өсләрен чистартып,
ташларын юып кайттым,
кәефем начар булса да,
күңелем хәзер якты...
Әллә кая кереп киттем —
бераз бушаттым эчне.
Ә яза башладым хатны
зур рәхмәт әйтер өчен —
улыма ярдәм иткәнсез,
күрсәткәнсез туганлык.
Ярый әле, анда сез бар! —
йөрер иде болганып.
Гәүдәгә әвен булса да,
беркатлы ул, нарасый,
күргәне булмады әле
җилнең агын-карасын.
Күз-колак булыгыз инде —
ул бит минем бердәнбер,
алай гына да түгелдер...
Ансын килгәч сөйләрмен...
Сау булыгыз! Казандагы
туганнарга да сәлам...
Тиздән күрешербез дигән
олы өметтә калам...
P.S.
Теге хәлләргә килгәндә —
ни әйтим? Тынычландым!..
Партбилет бәрабәренә
«милләтче» аты алдым.
Бу исем белән Казанга,
мөгаен, сыймамдыр мин...
Тынычланган йөрәгемне
шушы тигәнәк тырный...
Арынмыйча тигәнәктән,

кузгалырга теләмим,
барыбер арыначакмын —
үләм икән үләмен...»

Хатта нокта... Ә фикере
йөрәктә дәвам итә,
уй-хиснең туры агышын
бора да кертә читкә...
Килде дә басты алдыма,
ак кием кигән көе,
Баранов урамындагы
абзамның саман өе.
Саман дип... бәлки, түгелдер...
Эче биек һәм иркен.
Берничә җир тетрәнү дә
ега алмаган төртеп —
диварлары калын иде,
монастырьише иде...
Аннары җизни үзе дә
монда зур кеше иде,
аңа килде-китте торак
бирмәгәннәр, әлбәттә...
Хәзер ул — ярыйсы гына!
Ул чагында — бик кәттә!
Җизниләр килеп чыкканнар
Азия Ташкентына
«европа» кертүчеләрнең
беренче ташкынында.
Һәр эштә остаз булганнар,
үзләренә алмаш та
әзерләгәннәр... Һәм бүген
мөмкин остаздан башка...
Монда юк милләт гаебе...
Әмма тарих агышы
безнең баш белән күпләргә
үз бәхетен табышты...

...Тукта, абзый җиңгәбездән
сәлам язмаган хатта.
Бик матур яшиләр иде...
Мөгаен, бары хата —
онытқандыр дулкынланып,
хисләренә йотлыгып...
Аһ, бу җанның ашкынуы!
Аһ, бу тормоз юклыгы!
Тормоз дигәннән... Мәскәүдә
танышкан нефтьчебез
тормозына басты микән,
төшкәнче тәмам җебеп?
Юкса берничә кисәттек
без аны татарчалап...
Кул гына селтәде теге,
янәсе, җитәр чамам!..
Ул кеше минем хәтердә
яшәде шактый озак...
Өргән саен күтәрелгән
ялкындай кыза-кыза,
күңелемне кызыксыну
пешерде-аптыратты.
Хәтта берничә тапкыр мин

Әлмәткә шалтыраттым.
Исемен һәм фамилиясен
сорашалар сагаеп...
Без исемләп танышмаган
булганбыздыр, мөгаен.
«Сәлам, якташ!», «Сәлам, якташ!» —
барлык танышлык шушы...
Һәм без аны шактый юдык,
рюмкадагыга кушып.
Ике миллиард тонна нефть
алуны бәйрәм иткән
көннәрдә мин дә ничектер
барып чыктым Әлмәткә.
СССР икътисадының
бөтен серләрен, хәлен
белгән Байбаков* чыгышы
һаман да истә әле:
— Сугыштан соңгы елларда
илдәге бар төзелеш
татар нефте хисабына —
һәркем белергә тиеш! —
дигән иде чыгышында,
алкышларга күмелеп...

Мондый сүзне татарларга
әйтми иделәр элек!..
Шул залда да, фойеда да,
банкетта да күзләрем
меңләп кеше арасыннан
шул «якташ»ны эзләде...
Ялгышып, хәтта бер тапкыр
кемгәдер кул изәдем.
Ярар, алда гомер булса,
бер күрешербез әле...

Ә студент нишли? Укый.
Характеры тимердән.
Ул фән-белем гранитын
көне-төне кимерә.
Тулай торактан зарланмый.
Атна саен диярлек
бездә була, алып килә
бүлмәдәшен ияртеп.
Сыйлыйбыз һәм сорашабыз...
Тынычланып калабыз.
Ә киткәч, «Булса да булыр
икән!» дип сокланабыз.

**5**

Шулай көннәр туа торды,
кояш ашап тукланып.
Көннәр исә атналарга
гаҗәеп тиз тупланды.
Атналар исә, җыелып,
ай булдылар-киттеләр.
Кешеләр һәр берәмлектән
уңыш, шатлык көттеләр...
Үлеп китте олуг Генсек —

йолдыздай якты җисем,
Яр Чаллыга бүләк итеп,
үзенчә «яр»лы исем...
Ил тезгенен урап тотты
генсекларның яңасы.
Төсе бик уңган байракны
килде, ахры, манасы
кан төсле җете кызылга...
Башланды ыгы-зыгы.
Эш сәгатендә түрәләр
мунча кергәндә, кызып,
ләүкәдән халык алдына
аларны чыгарды ул...
Россияне айнытырга
һәрчак кирәк каты кул.
Һәм элекке коридорга
кайтты өмет яңарып...
Без ул чакта каян белик
яңа биналар барын?!
Капитал илләрендәге
үрнәкләр яраксыз дип,
без элекке сызымнарны
бераз яңартып сыздык.
Кагылмадык нигезләргә,
түбәләргә, идәнгә...
Түбә — һавага, ә идән
каты җиргә тигәндә,
үзгәрешләр нигә хаҗәт?!
Ныгыту җитә, сипләү!..
Ишекләргә яңа бикләр,
тоткалар куйдык ипләп...

Абзыйга да өмет кергән...
Партбилетны яңадан
кайтарырга... Шул хис белән
ул ярасын ямаган.
Ышанычын канат итеп,
туры Мәскәүгә очкан...
Эшен бераз кузгаткан ул!
Әнә шул куанычтан
кайтыр юлын Казан аша
оештырган бу юлы;
туганнарны да сагынган,
һәм, аңлашыла — улын.
Аннары — Казан чыгара
селенлы барабаннар...
Сызымнарны ишәйтергә
кирәкле икән алар.
Кыскасы, «сайрашыр өчен
өч-дүрт көн ара булыр —
понимаешь, менә моннан,
бугаздан, күңел тулы...»
Ике көндә барабаннар
мәсьәләсен хәл итеп,
дача дигән алачыкка
һава суларга киттек,
бер сайрашырга туйганчы,
сөйләшергә гөрләтеп —
хәсрәт утына су сибеп,
өмет утын дөрләтеп.

Алма исеннән исереп
йөрегән айлар иде.
Җир суынган, ә түбәдә
калайлар кайнар иде.
Көз гөлләре чәчәк атып,
күңелне бизәгән чак.
Мичле өйләрдә, йа бәхет,
кабына иде учак.
Шәһәр өйләрендә — салкын.
Бездә шәһәр йортлары
өй түгел бит, торак түгел,
бина гына нибары.
Шәһәр һәм ел фасыллары
яшәмиләр килешеп —
вакыт килми шәһәр якмый —
үлсәң үл шунда өшеп!
Ә бер ягарга тотынса,
вакыты килми япмый —
нигә шунда тиреҢ түгел,
күз яшең кайнап ятмый!..
Россия — гаҗәеп ил ул!
Җен тоткан, ахры, кысып —
кышта эшли җәйге эшен,
җәйдә эшли кышкысын.
Иң шәп тактадан-массивтан
койма коя чөй белән,
мебель ясый шул тактаны
ярган пычкы чүбеннән!..
Ходай биргән чишмә суын
сөттән дә кыйммәткәрәк
сата, ә чи нефтен бушлай
читкә биреп җибәрә,
һәм читтән шул ук нефтьтән
ясаган тарак, чиләк
сатып ала алтын түләп...
Бетереп булмый сөйләп...

Утырабыз абзый белән
шундый фикерләр йөртеп...
Өстәлдә — өчпочмак, сумса,
әлбәттә, табын күрке —
«Сибирская» дигәне.
Ул чиста, куәтлерәк.
«Три гроба»лар эчә-эчә
тукталды күпме йөрәк!
Укучы укытучысын
уздырырга тиеш дип,
татар эчә... Татар эчә,
үзен-үзе белешми.
Без, әлбәттә, тел ачкычы,
фикер уйнаткыч диеп,
абзыйның йөрәген саклап...
Сөйләштек аек көе.
— Җиңги нихәл? — дим абзыйга.
— Әйбәт...— ди, күз яшереп...
Бу «әйбәт»нең, ләкин бар күк
әйбәт булмаган сере...
Нәкъ шулай булып чыкты да:
абзый көймәсе комга
терәлә башлау белән үк

җиңгинең күзе тонган —
иренең һәрбер эшендә
эзләгән ул тап кына,
күрше-күләнгә сөйләгән,
шуны меңгә тапкырлап.
Адым саен оршышулар...
Мәсхәрәләү... Кимсетү...
Әйтерсең лә елан чаккан
котырган сыер сөтен
имеп үскән — һәр сүзендә
көтелмәгән явызлык...
— Кыскасы, бергә торабыз,
ә яшимен ялгызым.
Кайдан эләккәндер аңа
максималистлык чире —
ачуланса, нәфрәтен ул
кадый да, алмый кире.
Газаплансын, үлсен кеше —
аңарга рәхәт кенә.
Ялкынсына шушы чире
бер тузан бөртегеннән...
Кичерә алмый үзенең
һәм кешенең хатасын —
үзен-үзе белештерми,
хет дөньясы шартласын!
Партиядән куылуым
катастрофа булды.
Көне-төне җәберләде,
җәберләнде буылып...
Үзе тудырган хисләргә
үзе сыя алмады,
үзе яндырган утларны
үзе тыя алмады...
«Испоганил душу» диеп,
бөтен чикләрне узды:
«Асылын, ичмаса!» диеп,
элмәкләнгән бау сузды...
«Милләтче генә түгел ул,
ул — мазохист, ул — садист...»
диеп, парткомга хат язды —
менә шуңа китте ис!
Хыянәт, брат, хыянәт!..
Ә гыйшык нинди иде!..
Ул мине Ширин Фәрхадне
сөйгәннән артык сөйде.
Ул — күләгә кебек назлы,
пляж комыдай кызу...
Уналтысы тулганчы ук
минеке булган кыз ул!
Мин — студент. Ул — мәктәптә.
Таныштык без кинода.
Икебезгә насыйп булды
соңгы шешә лимонад.
Бүлешкәндә, кызый әйтте:
«Серебез уртак булсын...»
Һәм бу сүзләрдә бар иде
ниндидер көчле тылсым.
Янәшә буш урын таптык...
Кая ул кино карау?!
Ул, песи баласы кебек,

һаман елыша бара...
Атналар, айлар елышты...
Бер ел да үтеп китте.
Һәм шушы бер ел эчендә
ул мине шагыйрь итте.
Нәзәкатьле үпкәләүләр,
кочагымда елаулар
үзлегеннән әйләнделәр
рифмалашкан юлларга.
Рифмасыз шигырьләрне мин
шигырь диеп танымыйм.
Ритм прозада да бар ул!
Рифма — шигырь кануны.
Рифмага ияреп, фикер,
челтәрләр үрә-үрә,
ир куйнына кергән кыздай,
хис кочагына керә...
Ничек минеке булганын,
яши алсам сау-таза,
Пушкин үзе көнләшерлек
поэма итеп язам.
Әхлак анда каты иде!
Һәрвакыт уяу!.. Сакта!..
Ләкин тугызны бетергәч,
кызый калды корсакка...
Аның мине каргаулары,
елаулары илереп...
Кочаклашып әрләшүләр
киноларга керерлек.
Котылу юлын эзләүләр,
оятка бата-бата...
Мәхәббәт — изге нәрсәдер...
Безнеке менә — хата...
Әлбәттә, аны төшерде,
ләкин калды бәласе —
шул эшләрдән дип әйттеләр —
була алмый баласы...
— Ничек? — дия генә алдым...
— Шулай! — диеп кырт кисте,
һәм тышка ук чыгып китте,
көйдән качкан сүз төсле...
Моң тулып калды бүлмәгә —
тыңла, тыңлама — керә,
тибүе шактый ешайган
йөрәккә давыл өрә,
чайпалта тойгылар күлен,
дулкынын күзгә бәреп...
Тәрәздән болдыр күренә...
Тетрәтеп җилкәләрен,
абзый елый, сөялгән дә
болдыр баганасына...
Ара-тирә башын чайкый,
күлдән чыккан ат сыман...
Чал чәчләрен учлап тота,
киерелә, иелә...
Абзый елый арка белән,
җилкә белән, бил белән,
елый бөтен гәүдә белән!..
Җиргә, күккә карамый.
Елаган чакта, ирләрне

юатырга ярамый.
Юк, ярамый юатырга
ирне елаган чакта,
ул елый, бөтен Җир шарын,
күк гөмбәзен кочаклап...
Хатын елый йөрәк белән,
ә ирләр — акыл белән...
Ирләр елаган чагында,
аларга якын килмә —
юләрлек эшләүләре бар,
үкенеч булырлыкны...
Ирләр елаган чагында,
хәтта вакыт та туктый...

Абзыйны калдырып торыйк —
туйганчы бер сыктасын,
алма исе сеңгән җилгә
җибәреп хис нуктасын.
Туктар әле вакыт җиткәч,
төкәнгәч яшь чишмәсе —
акмый калган ачы яше
йөрәк итен тишмәсен.
Ачар әле, кирәк тапса,
ябык калган серен дә...
Миңа абзый чайкала һәм
чүгә кебек күренде.
Йөгереп чыктым болдырга.
Төсенә ак чыгарган...
— Хыянәт — тәмуг утыдыр,
мөмкин түгел чыдарга.
Әллә нишләп киттем әле...
Йөрәкне уйлар ялмый.
Бармы кәгазь? Мин аларны
эчемдә йөртә алмыйм...
Кәгазь бирдем. Абзый язды,
өстәлгә сеңә-сеңә.
Язганнарын, ерта барып,
тутырды кесәсенә.
— Әле барып чыкмый,— диде, —
әмма язуым ярый,
ертыкларны, тынычлангач,
мин җыеп, таслап карыйм —
барыбер анда нәрсәдер
бардыр диеп ышанам —
язганда гына шагыйрьнең
җаны чирдән бушана...

Иртәгәсен мин абзыйны
Ташкентына озаттым...
Мин кыймадым, ул ачмады
серендәге йозакны...

**6**

Бездә буран бурый иде,
авыр февраль бураны...
Тагын Генсек үлеп китте,
партиядән сорамый,
куеп аны авыр хәлгә
соцлагерь каршысында,

Бородинода нык томау
алган Наполеон сыман...
Җиңә алмады илдәге
зур җитешсезлекләрне.
Тезген бушаганны сизеп,
халык... елап җибәрде.
Шатланырга тиеш иде!
Юк, халык юртак ише —
дилбегәне тарткан саен
тизләтә йөгерешен.
Ә дилбегә бушадымы,
безнең халык туктала...
Һәм партия дөрес итә
тотып безне нуктада...
Халык арып беткән иде
карап илләр аркасын.
Халык көтә иде кемнең
дилбегәне тартасын,
юкса җиңелгән илләр дә
йөгерә бездән алда...
Без һаман яши бирәбез
айныкын айга ялгап...

Минем «милләтче» абзама
өмет кергән яңадан...
Гаҗәп! Россиядә өмет
яңабаштан яңара
ил башлыгы үлгән саен...
Уйлап кына кара син —
нинди бездә халык белән
хакимият арасы!..
Абзый тәмам гарык иде
теге шакшы яладан...
Көтмәгәндә шалтыратты
эшемә башкаладан —
аудиенция көтәм, ди,
аңларлар, ди... Ышана!
Кичә көндез ЦДЛга
барып бераз «бушанган».
Әйбәт булган — кемне генә
очратмаган, күрмәгән!..
Ходай сакласын, бәхәскә
беркем белән кермәгән.
Николай Старшинов һәм
Вадим Кузнецов* белән
бер өстәлгә туры килгән:
— Ну, брат, көлеп үләм
дип торам, Старшиновның
частушкаларын тыңлап —
мең оятсызлык туплаган
солидный ике томга**,
ләкин бастырып булмый, ди...
Бездә үткен сүз белән
әхлак көрәшә башласа,
үткен сүз, шиксез, үлә,
үлә буылып, тончыгып,
гениальный булса да...
Юк, ярамый, кертеп бикләү
халык сүзен кысага.
Менә Брежнев турында

күпме анекдот яши?!
Һәр анекдот — бер лекция
йә бер доклад тиңдәше.
«Белем» җәмгыяте, килеп,
лекция сөйләп китә.
Бу да әйбәт!.. Анекдотка
нинди лекция җитә?!
Акылы үсү буенча
ил ирешсә уңышка,
аңа, законнарны узып,
анекдотлар булышкан!

Иртәгә шалтыратам, дип,
ноктасын куйды абзый.
Чак әйтеп өлгерә алдым
йөремә, диеп, азып...
Иртәгәсен кичкә таба
шалтыратты. Тавышы
тонык иде, нурсыз иде...
— Бу юлы да ялгыштым...
...Кайнап теленә утырган
сүзләрен чак кубарып
сөйләп бирде — персоналка
тик катлаулана бара.
Кемдер анонимка язган —
бозган рәтләнгән эшне,
уяткан йөрәгендәге
төзәлә язган шешне.
Кем кулы икәнлеген ул
чамалый, тик ышанмый...
Ләкин абзый никтер чишми
телендәге тышауны.
Иртәгә ул Оренбурга
очачак, билет булса.
Ә аннан — кабат Мәскәүгә,
Оренбурда юл уңса...

Ярар, абзый Оренбурга
билетын юллый торсын...
Анонимка язучының
бармагы корый торсын...
Без, сәмруг кошка утырып,
Ташкентны урап кайтыйк,
ни булганын җиңгәбездән
белешеп, сорап кайтыйк...
Бәлки, абзый яшерәдер,
авыр булса да әйтим,
«милләтчелектән» дә яман
ниндидер җинаятен —
турыдан-туры җиңгинең
бәгырен кимергәнен,
горурлыгын таптаганын,
өметен җимергәнен...
Бәлки, хыянәт иткәндер,
җиңги аны тоткандыр,
тоткандыр да көнләшүдән
берәр дару йоткандыр...
Бәлки, җиңги туганнарын
читкәрәк тибәргәндер,
үзенекеләрен — безне —

өскәрәк күтәргәндер...
Бәлки, мал бүлешкәннәрдер...
Җизниләрдән калганны...
Ничек кенә бүлешсәң дә,
мал бүлешү — алдану...
Җанны боздай суытырга
сәбәпләр иксез-чиксез...
Аны майдай эретергә
юкмыни соң кайнар сүз?!
Татар телендә юкмы ул?!
Юкмы урыс телендә?!
Телдә булмаган сүзләрне
ым белән, күңел белән
җиткереп була лабаса,
башка юллар белмәсәң!..
Әйе, була!.. Тик тыңлаучың
ишетергә теләсә...
Күрәсең, безнең җиңгинең
йөрәк колагы каты...

Без менә сәмруг кошсыз да
Ташкентны урап кайттык,
чөнки сәмруг кош килгән дә
безне бик озак көткән,
аннары, ачуы ташып,
каядыр очып киткән...

Мөгаен, абзабызда да
шагыйрьлек тормый кайнап —
ташны да эретеп була,
җан җылың белән җайлап!..

**7**

Ак ялыннан көртләр сибеп,
арып бетте ак юрга —
тәмам күмелә яздылар
төлке уйнаган урлар.
Март аеның дәртле тыны
эретте көрт өсләрен,
бриллиантлар сирпеделәр
аллы-гөлле төсләрен.
Алар чәчрәп күзгә керде,
күздән күчте йөрәккә,
ә йөрәктә әйләнделәр
назлы, якты теләккә.
Ә теләкләр шундый кайнар,
шундый дуамал, азгын —
кояштан тартып төшереп,
җиргә яткыра язны.

Шундый көннәрнең берендә
безнең студентыбыз
бер кыз белән килеп керде:
— Менә, таныш булыгыз!..
...Кызны бер генә сүз белән
әйтеп була «Ару!» дип.
Ә тирәнрәк шәрехләсәк —
егетенә пар иде.
Гомер буе күзәтәмен

гаҗәпкә кала-кала:
ирләр үзенә йөз белән
охшаган хатын ала!
Ахры, кеше үз-үзенә
матурлык эталоны.
Үзенә охшаш кешегә,
ахры, шул этә аны.
Һәр кешедә әтисенең,
әнисенең чалымы!
Бәлки, шул өлге буладыр,
күзебездә чагылып?!
Шуңа күрә дә ышанам,
уйлап карап бер яктан:
Адәмне Аллаһ үзеннән
өлге алып яраткан...
Никтер ул сары балчыктан
тагы да камыр басып
тормаган — тарткан да алган
Адәмнең кабыргасын,
һәм барыбызга билгеле
бу эшенең дәвамы —
Аллаһ барлыкка китергән
анабызны — Хаваны.
Адәмнән дә чибәррәкне!
Өлгесеннән дә микән?..
Ярлыкагыл, мин бәндәне,
болай уйламам бүтән...
Моңа сәбәпче — теге кыз!
Ул гаепле, ул бозды...
Ярлыкагыл, мин гөнаһлы —
итагать чиген уздым...

Кыз нефть ягыннан икән...
Түгәрәк гаиләдән...
Стипендиягә өстәп,
өеннән килә ярдәм.
Әти-әнисе эшлиләр...
Кайда булсын? — нефтьтә.
Абыйсы бар. Ул — Әфганда.
Тиздән кайтыры җитә.
Бер генә балл аркасында
керә алмыйча калган
институтка... Нәтиҗәдә —
армия сафы, Әфган...
Әтиләре әйткән вузга
барган булса әгәр дә,
йөрер иде тауда түгел,
менә монда — шәһәрдә...
Ул, әтисен тыңламыйча, —
Уфага, нефтянойга...
Әйтерсең лә аңа кемдер
урын әзерләп куйган...
Ә әти аны Казанда
юрфакка кертә иде —
өйдә юрист булсын, дигән
бер хыял йөртә иде...
«Сельхозны» бетергән килеш
әтисе әнә никтер
«Татнефть»тә эшләп йөри —
нефтьче булып китте...

Үзе экономист була,
әгәр дә укый алса...
Юк, юк, куркыныч янамый —
уку бирелә ансат...

Сүзгә егет тә кушылды,
күзен түшәмгә терәп:
— Безнең бер проблемабыз бар...
Һәм сездән киңәш кирәк...

Ә проблема шундый икән —
кыз корсаклы... ике ай...
Охшаса да охшар икән
атасына бу малай!..
Алмагачның бу алмасы
үзеннән ераккарак
төшкән дип уйлаган идек —
бер дә юк икән ара.
— Нәрсә эшләргә уйлыйсыз?
— Өйләнешергә исәп...
— Киңәш көтәсез... Әгәр без
иртәрәк әле, дисәк?
— Барыбер өйләнешәбез! —
дип кырт кисте кыз бала —
беренчесен төшергәннәр
бик еш баласыз кала...
— Өйдәгеләр беләләрме?
— Без дә бер атна элек
үзебезнең хәлебезне
врачка барып белдек...

Телем белән әйталмагач,
бу «олы куанычны»,
Казаннардан Ташкентларга
сагынычлы хат очты.

Ак болытлар арасыннан
кырларга карый-карый,
очсын әйдә... безгә дә бит
бераз тын алу ярый —
исебезгә төшерергә
алар кебек чакларны...
Нәрсә, бездә юк идеме
йөрәк чәчрәп шартларлык
кайнар хисләр, дуамаллык,
гүзәл, сукыр кыюлык?!
Ничәбез соң соңгы чиктә
кала алды тыелып?!
Йә, кайсыбыз мажарасыз
башлы-күзле булды соң?!
Болар да беренче түгел
һәм булмаслар соңгысы!..

Буйдак нигә буйдак калган?
Гыйшыкта азмаганга —
озак, төптән уйламыйча
никахка базмаганга.
Ә озак итеп уйлангач,
өйләнергә курыккан.
Тилелектән курка-курка,

эше киткән шырыкка...
Йә, йомыгыз күзегезне!..
Чумыгыз хатирәгә!
Күз алдыгызга килдеме
чик бозулар... иркәләп?!
«Нишләттең?» диеп елаулар...
«Нишләдем?» диеп яну...
Билләһи, бу ике сүзне
Җирдә һәр кеше таный,
һәркем бертөрле үк аңлый,
саклый бирә кадерләп,
җаны тыныч чакларында
чакырып ала хәтердән.
Тик кабатлый алмый инде
элекке кайнарлыкта —
юллар суыткан аларны,
юлларны еллар йоткан...

Абзыйлардан хәбәр көттек.
Ул үзе килеп төште,
кыектан кубып,бозбармак
карга кадалган төсле —
балкып тора, күзләреннән
сирпелә көләч нурлар...
Ә безне борчыган иде
«Борчылыр...» дигән уйлар.
Ныклап аякка басмыйча
өйләнергә ашыгу —
беләбез ич — бәхетсезлек
дигән сукмак башы ул.
Көчәнүдән җыгың чыгып
сөйрәү тормыш арбасын
шәп бәйге юртагыннан да
йөк аты гына ясый...
Абзый борчылмаган, әнә
мыегына да элми...
— Ник иң кирәген язмадың —
кыз татармы, түгелме?
— Татар кызы,— дидек,— татар!
— Төсе-буе чибәрме?
— Чибәр!— дигәч, ул тавышсыз-
тынсыз көлеп җибәрде...
Әйе, бар андый көлү дә,
ләкин ул очрый сирәк,
курыкканга — куш шикелле,
йөрәкне ертып керә,
билгесез бер дару кебек,
шом сала-сала эри...
Һәркемнең үзенә генә
билгеле аның сере.
Абзыйның якты өмете,
бар чикне үтеп китеп,
чарасызлык кыясына
бәрелгән кебек иде..
— Ну что ж, өйләнәбез!— диде, —
безнең язмыш хатасын
ничек инде, күрә торып,
улыңнан ясатасың?!
Селенлы барабаннарның
хәлләрен хәл итәм дә

шул ук көнне, Ходай кушса,
кыз сорарга китәмен.

Абзый кулын шапылдатып,
ышкыды бар көченә —
кемнәрнедер сытты кебек
ике учы эчендә.
Чабуына хаиннәрчә
ут төртүчеләрнеме?..
Әллә күрмәүчеләрнеме
аның йөрәк әрнүен...
Әллә Мәскәү төчкереген
бомба дип кабул иткән
Ташкент партчиновникларын
уып ком итә микән?
Әллә шулар арбасына
утырган хатынынмы?
...Кайный эчләр утлы үчтән,
йөрәктә давыл тынмый...

Әллә бәс кунган хисләрен
җылыттымы ул ышкып?
Мин Россия гадәтенчә
рюмка белән булыштым...
Беренчесе уебызны
тиз һәм җитез иттерде.
Икенчесе телебезгә
сүзләр куып китерде.
Ә өченчесе ачтырды
күңелдәге бикләрне...
Хисләр өчен юкка чыкты
дөньяның бар чикләре.
Кинәт минем искә төште
дача, болдыр, тәрәзләр,
абзый кесәсенә чумган
серле ертык кәгазьләр...
Алар, гүзәл бер чир булып,
күңелемә йоктылар,
исләремә төшкән саен,
тынычлыкны йоттылар,
кардиамин йоткан кебек.
Дөп-дөп типте йөрәгем...
Коерык очын күрсәткән сер
бирде генә кирәкне...
Кеше серсез — кеше түгел,
сүз-күзле бәдән генә!
Кеше итәр өчен Ходай
сер бирә адәменә.
Кайсының сере роман, җыр,
поэма булып әрни,
гасырдан гасырга күчеп,
баета күңелләрне —
кешене Кеше итүдә
кадәри хәл катнаша,
аның Җирне бизәр өчен
килгәнлеген аклаша...
Кайсының сере үзендә
әйләнә яман чиргә,
Япь-яшь килеш газиз башын
китереп тыга җиргә —

йә кадала хәнҗәр булып,
йә ата көпшә терәп...
Андый серләрне белүдән
белмәвең хәерлерәк.
Матур серләр илһам бирә,
яман серләр исертә...
Йа Ходаем, саклый күрче
яман чир, яман сердән!..

Ләкин түзмәдем, ясадым
сергә таба адымны:
— Теге, ерткан кәгазьләрне
җилләр урламадымы?
— Урлавын урламадылар...
Җан тирләми кызудан...
Хисләр кайнап торган чакта,
никтер сүзләр боз була.
Мин аларга шырпы төрттем
бакчабыз почмагында...
Шул почмакта тәүге тапкыр
ул минем кочагымда
кыз түгел, ә хатын булып
елады куанычтан.
Аның сихерле яшьләре
тамдылар шушы учка.
Куе чия ышыгында,
җайлы җәйге сәкедә,
марля чыбылдык эчендә,
ничектер сизмәдек тә
назларның, үбешүләрнең
тыеп булмас теләккә
әйләнгәнен көпә-көндез —
һәм... сандугач келәттә...
Мин дә көйгән иренемне
шул яшьләрдә чылаттым...
Нинди бәхет — сөйгәнеңне
бәхетеннән елату!
Җаным гына тынычлансын —
барыбер моны язам!
Есенин ук булмаса да,
күрсәтер әле абзаң...

Иртәгәсен без булачак
киленкәйне-чибәрне
Әлмәтенә — әтиләрен
әзерләргә җибәрдек.

**8**

Татарстан юлларында,
кырык абына-сына,
ниһаять, без барып җиттек
нефть башкаласына.
Болыттан котлет кыздырган
факелларны күргәчтен,
адым саен кара майлы
кар суына кергәчтен,
газ кермәгән авылларны
кабат искә төшереп,
абзый төкерексез генә

куйды шунда төкереп.
— Аның каравы бирегә
яз иртә килә!..— дидем...
Абзый монда эчәр суның
беткәнен белми иде...
Әйдә, белми генә торсын
җир тетрәү дә булганын —
һәр пешмәгән шагыйрь кебек,
тәнкыйтьтә һай уңган ул.
Боларын да сөйләп, әллә
чыгарттырыйкмы парын?..
Юк, ярамас — кызар гына,
ул ярсыр гына бары...
Әнә инде улына да
кырыс карый башлады —
керфеген тәнкыйтьли кебек
җыерылган кашлары.

Тукталдык кунакханәгә,
юындык, ыспайландык,
буфетка төшеп тиз генә
тамак та ялгап алдык,
һәм сузылган гына идек,
ял биреп умырткага,
кемдер уч йомшагы белән
безнең ишекне кага.
Булачак килен икән ич —
эзләп тапкан хәбәрсез,
чибәр генә түгел икән,
уңган икән һәм әрсез...
Бераз гына төсе качкан.
Хәер, шундый чагы бит!..
Ләкин аның күзләрендә
караңгы нур чагылды.
Ул нур безгә дә ягылды,
басты шатлык чаткысын...
Һәм кыз, булачак иренең
киң кочагына посып,
сулыгып елап җибәрде...
Без калдык аптырашта,
Әйтерсең кояш урнына
кар төште безнең башка.
Яшенә чыланган сүзләр
салдылар безне утка:
— Әфганнан абыем кайтты...
 кайтты цинк табутта...

Тораташтай катып калдык...
Телне өянәк тотты...
Бәхет тудырырга килдек,
ә безне кайгы йотты.
Аның кара карынында
киттан йотылган балык
хәлендә калган шикелле,
хәтәр дөньяда калдык...
Безнең киләсен беләләр...
Торганнар әзерләнеп...
Нишлисең — язмыш елгасы
болгаткан бүген ләмен...
Ә иртәгә ул тоначак,

дәвам итәчәк тормыш:
кем үләчәк, күмеләчәк,
ә кемдер тормыш кормыш...
Кайгы — шатлык, уен — уймак
һәрвакытта янәшә.
Шуларны кавыштырмаска
тырышу — була яшәү.
Кавышкан мизгелләрдә дә,
табып таяныч-терәк,
ерткычланмый, мескенләнми
кала белергә кирәк...
Һәм безгә дә чигенү юк.
Бу — акыллы җүләрлек!..
Тиздән киләбез, дип, кызны
без кайтарып җибәрдек...

Чупай ташыннан салынган
өйнең ишегалдында
бихисап күп кеше иде,
бихисап күп машина...
Без күтәрелдек өченче,
иң югарыгы катка.
Өч табуретка өстендә
цинктан табут ята.
Түр очында — фотосурәт.
Аһ, нинди егет әрәм!..
Аны утка ташлаучыны
ничек туфрак күтәрә?..
Ватан өчен булса әле!..
Әфганда нинди Ватан?..
Кемнәрдер хатасы өчен
егет табутта ята.
Баш очында ике солдат —
озата кайтучылар —
яңакта төер уйнатып,
торалар чак-чак чыдап...
Үзләрен дә шундый язмыш...
Юк, юк, Ходай сакласын!
Һәр солдатның тере килеш
килә өйгә кайтасы.
Әнә бер кыз... Кулларында
кечкенә шул ук рәсем.
Ул елап шешенеп беткән,
сөйгәнедер, күрәсең —
хат язышып торганнардыр,
булса да хәрби чикләү...
Бер медаль... военкоматтан
китергән мендәрчектә.
Әти-әнисе кайда соң?..
Булачак кодагыйга
кухняда укол салалар...
Бераздан монда чыга...
Ул чыкты һәм без таныштык.
— Менә бит ничек булды,
гафу итегез инде...— дип,
тотты ул минем кулны.
Нигә ул гафу үтенә?
Кем өчен гафу сорый?..
Аның аркасында мәллә
Рәсәй сугышсыз тормый?

Әлбәттә, сер саклый-саклый...
Килеп чыга аннары
арабызда Корея һәм
Вьетнам ветераннары...
Ватан мәнфәгатьләренең
кайда икән чикләре?
Без бит бала үстермибез,
бары... пушка итләре...
Бер офицер да табутны
озата кайткан икән,
кода әнә шуның белән
кабер җайларга киткән.
Офицер һәм военкомат
ашыктыралар гүргә...
Ә сәгать өченче киткән...
Исәпләшмиләр бер дә
йола белән, гадәт белән,
кеше теләге белән —
ашыгалар, әйтерсең лә
җинаять эшләп үлгән...
Әнә бит, медале дә бар,
илебез исеменнән...
Аны күмәчәкбез... илгә
нәф(е)рәт хисе белән...
Әнә этисе дә кайтты...

Йа пәйгамбәр!.. Йа Хода —
теге... Мәскәү... тәэминатчы —
безнең булачак кода!
Абзыем да, миңа төртеп,
аңа таба ым какты...
Менә бит нинди шартларда
аны эзләми таптык!..
Ә ул безне танымады —
күзләренең хәтерен
тутыктырган иде, ахры,
улларының кабере.

Автоматтан күккә атып,
җиргә бирдек табутны,
сискәндереп фәрештәнең
амин! дигән вакытын.
Офицерның ятлап алган
хушлашу сүзе салкын —
ахры, күп кабатлагандыр,
кырыс теленә салып...
Күз яшьләре кайнар иде,
әчерәк һәм тозлырак,
чөнки нәфрәт, каргыш уты
күзне эчтән кыздыра,
кайнау хәленә җиткерә
җанны да, тән сутын да...
Һәркем аңлый — халык яна
олы хата утында,
берәм-берәм, шырпы кебек,
сызыла да юк була.
Шырпы һәр сызылган саен,
җанда имән егыла —
бик күп җил-давыллар кичкән,
рухны тоткан имәннәр...

Хата өчен үлгәннәрне
күмү авыр икән лә!..
Сап-сары балчык, мәңгелек
караңгылыктан чыгып,
куркытты имәндә оя
эзләгән сыерчыкны...
Менә тагын яңа кабер...
Ил кәефе кәекми...
Һәм беркем дә үз өстенә
алмый илдә гаепне...
Ватан мәнфәгате дигән
бәхәссез идеянең
бәхәслелеге күренде,
ә кая китте яме?..
Җавапсыз сорау эзеннән
чатнады ил нигезе...
Ә теге матур идея
бүген — коры имезлек...

Балчыклы аякларны без
яз нуры сеңгән карга
сөрттек тә, кунакханәгә
кайтып киттек йокларга —
мәет чыккан өйгә ничек
кунак булып барасың?!
Ә шулай да якын икән
туй һәм кабер арасы!
Кунакханәдә ресторан.
Ашадык кичке ашны.
Авыр булды, әйтерсең лә
кашыкта кабер ташы.
Килүебез максаты да
телебезгә чыкмады...
Иртә кичтән хәерле, дип,
менеп ятып йокладык...

Ләкин күзгә йокы керми —
артык арылгангадыр...
Искә төшеп, сорап куйдым:
— Ничек анда Оренбур?..

Өч урынлы бүлмәбезнең
тыныч караңгылыгы,
куерып, ахры, абзыйның
тын юлына тыгылды.
Абзый йөткерә башлады...
Йөрәк белән йөткерә.
Әкрен генә әйтеп куйды:
— Дару... валидол кирәк...

Ә ул бездә каян булсын? —
даруханә түгел ич...
Машинада аптечка бар,
ерак калды «Москвич»...
— Алайса, бер йотым коньяк...—
шешә портфель төбендә...
Уф, җибәрде... Шундый кысты,
чак китмәдем «тегендә»...
Оренбур ярыйсы булды...

Сөйләрмен... Хәзер йоклыйк...

Бераздан өчебезне дә
йокы суырып йотты.

Уяндык ишек шакудан...
Март кояшы тилергән —
төньяктагы бүлмәбезгә
чагылып килеп кергән.
Абзый, торып, ишек ачты.
Булачак кода килгән,
кайгысы күз төпләренә
сыланып кара көйгән.
Үзе тырышып елмая,
ә җаны кан коя, шәт...
Елау-көлү уртасында
сәер була кыяфәт...
Шаярган була:
— Торыгыз!
Сезне зур эшләр көтә —
ресторанда, банкетныйда
бәлеш суынып бетә.
Хатын минем инде анда,
җыеныгыз, төшегез...
Нинди чакка туры килде
сезнең изге эшегез...

Чыгып китте... Мыгырдана-
мыгырдана җыендык.
Инициатива бездән
ычкынган күк тоелды.
Төштек, таптык банкет залын.
Бай, затлы, тәмле өстәл
Мәскәүне, теге хәлләрне
кабат төшерде искә...
Тел очына төшкән сорау
әверелмәде сүзгә.
Ул безне танымый иде —
шулай күренде күзгә...
Булачак кодагыйга да
төн салган авыр эзен.
Ул бирегә мәҗбүр итеп
китергән инде үзен.
Утырдык. Булачак кода,
әңгәмәбез тезгенен,
кулларына урап тотып,
сүз башлады тиз генә:
— Өебездә кабул итеп
булмады бу юлыга...
Әнә ниләр көтә икән
безне гомер юлында...
Бер читкә куеп торыгыз
тартынуларыгызны,
йоласына туры килсен —
сорагыз безнең кызны!..

Болай ук булыр диеп, без
көтмәгән идек һич тә.
Күрәм, абзый, телен тешләп,
тыелып тора көчкә.

— Сорарга дип атлап килеп,
сорамыйча калмабыз —
сез теләп бирер булсагыз,
без бик теләп алабыз...

Сөйләшүләр-килешүләр
шактый булды, әлбәттә:
Казанда язылышалар,
туйлар узар Әлмәттә,
чөнки Ташкент артык ерак,
туганнар да аз анда.
Махсус автобус җибәрер —
рәхим итсен казаннар...
Никах укытмаска микән,
дигән сүз дә кузгалды.
Бусы — кодагый тәкъдиме.
Абзый уйлана калды —
тайгалакта торган килеш
бу хәрәкәт кирәкме?
Кисеп ату булмасмы соң
бу тагы бер терәкне?
Алай дисәң, киленнең дә
хәленә керү кирәк —
оялып түгел, куанып
яралсын яңа йөрәк.
Беркем дә сүзен әйтмәде...
Тынлыкта уй куертып,
үзебездә үзебезне
җиңә-җиңә утырдык,
һәм җиңдек тә ахыр чиктә —
ризалаштык тәкъдимгә:
яшьләр, артык шаулашмыйча,
таянсыннар хак дингә.
Никахны да монда гына
укыту хәерлерәк —
гайбәт этләре Казанда
чәрелдәбрәк өрә...
Төрле тулай торакларда
яшьләрне газапламыйк,
ничек тә булса боларга
фатир йә бүлмә табыйк...
Ә бала тугач, яшь ана
укысын читтән торып...
Кыскасы, яшьләр өчен без
генераль план корып,
Казанга таба юл тоттык,
абзый белән икәүләп...
Безгә карап, сәер генә
елмаеп калды Әлмәт.

Бик озак сүзсез кайттык без,
тыңлап көпчәкләр шавын.
Һәм абзый кешнәп җибәрде
куркытып һәм каушатып:
— Кыз сорарга барган идек,
кайтып киләбез кире,
умора, брат, умора —
егетне кызга биреп...
— Оренбурга нигә бардың?
Нәрсәң калды ул якта?..

Күчик алдагы бүлеккә —
ул бүлек нәкъ шул хакта...

**9**

— Теге эш пеште дигәндә,
бик хәтәр җилләр искән —
аноним хат килеп төшкән
ЦеКага минем өстән.
Хәзер үк җавап бирәм син
сораячак сорауга —
анда мин гаепләнәмен
сабый бала урлауда.
Әйе, әйе... Бу гаепләү
нигезсез түгел бер дә —
аны, бәллүр пычак итеп,
йөрәк эчендә йөртәм.
Кирәкмәгәнчә борылсам,
кадалачак, сыначак...
Сынмады, йөрәкне тишеп,
дөньяга чыкты пычак...

Беренче бала төшерү
кыйммәткә килде безгә —
хатынымның гөлбакчасы
керә алмады көзгә,
һич төерләнә алмады
чәчәгенең җимшәне.
Бу кайгыны сер иттек без,
беркайчан да чишмәдек.
Дәваландык иксез-чиксез...
Бармадык кайда гына!..
Акча шуңа китә торды —
булмады файда гына.
Исеңдәдер, ГДР* да
өч тапкыр булдык ялда...
Юк, алар да бер сынганны
җибәралмады ялгап...
Барып чыктык бурятларга —
Тибет медицинасы,
бәлки, безгә күрсәтер, дип,
үзенең могҗизасын.

Анда һәр дацан** каршында
дәвалыйлар тибетча.
Дәвалаучылары кызык:
учларны ала учлап,
ике кулы белән синең
беләкләреңнән тота,
һәр дүрт бармагы пульсыңнан
җан хәбәреңне йота...
Иң алдан үзем утырдым.
Бармаклары беләктә.
Әкрен генә бер-бер артлы
бөтен чиремне әйтә
башлады бу... Куркып калдым,
тартып алдым кулымны —
нигә, нигә булыйм әле
артык белү колы мин?!
Чирен яшергән үлә, ди,

чирен белмәгән — яши!
Һәм яши ул җанындагы
өмет белән берләшеп...
Табибыбыз шаккатырды —
белгәч без телне йоттык:
ул хәрби академия
бетергән булып чыкты.
Аннары алты ел буе
белем алган Тибетта.
Шунда аңа ламалардан*
кан телен аңлау йоккан.
Кан тәндәге һәр күзәнәк
хәлләрен туплап ага.
Кан сөйләшә, хәбәр бирә
аңа колак салганга...
Ә җиңгәңнең кан тибеше
сөйләгән сүзләр безнең
өметнең черек тамырын
бик тә вакытлы өзде...
Хыял, өметкә әйләнеп,
безне исерткән булган.
Икебез дә бер вакытта
без айнып киттек бугай.

Җиңгәгез озак вакытлар
елап, уфтанып йөрде.
Ул тәмам аңлаган иде:
б а л а Ир итә ирне,
хатын-кызны Ана итә —
ача бөек асылын...
Аның канатлары төште,
яшәп китте басылып.
Төшенкелеккә бирелде,
бушады нервылары —
хәтта психиатрга
күренгәләде барып...
Ә миндә көннән-көн артты
эти булу теләге.
Кайчакларда ул теләкне
нишләтергә белмәдем.
Җиңгәгезне, назга төреп,
күп тилерттем түшәктә.
Ләззәтеннән ул тырнашты,
ул бетерде тешләп тә...
Табигатьне җиңәм диеп,
дулатты бөтен дәртен,
әмма ләкин үзгәрмәде
гөлбакчадагы тәртип —
наз чәчәкләрендә җимшән
төерләнә алмады...
Уллыкка бала алудан
башка әмәл калмады...

Һәм без шулай уллы булдык...
Менә шуның хикмәтен
ЦеКага хәбәр иткәннәр,
шактый дөресен әйтеп...
Ә дөреслеккә килгәндә —
аны өч кенә кеше
белә кояшлы дөньяда,

бөтен серенә төшеп:
мин, җиңгәң һәм улыбызны
табып биргән бер хатын...
Ахры, зурдан түләтерләр
шушы дөреслек хакын...

Мин улымның чын этисе —
бит минем орлыктан ул...
Серебез аңа ачылу —
минем бар курыкканым.
Әнисенең чын әнисе
булмавы ачыкланса...
Йөрәгенә ялкын кабар...
Әйтүе генә ансат...
Җиңгәң үзе тапкан итеп
җайладым... Ышандырдым —
эшеннән китеп ул бер ел
Уральскида торды.
Декретын шунда уздыра,
диеп хәбәр тараттым —
менә нәрсәләр эшләтә,
брат, артык ярату!..
Яратма икән өзелеп,
яратма икән шашып.
Нәфрәте андый сөюнең —
дәһшәтле яшен ташы:
аңның күзен сукырайта,
хисне заряд иттерә,
йә шартлый, йә үзен-үзе
ул көйдереп бетерә...

«Улың бар...» дигән хәбәрне
күрсәтеп йөрдем өч көн.
Командировка алдым да,
мин Оренбурга очтым,
чөнки бала анда туды...
Йә, беразга тукталыйк —
Чаллыга килеп җиткәнбез,
кереп чәй эчеп алыйк...

— Чаллы түгел, Брежнев, дим —
таштан язылган, актан.
Әнә портреты тора,
ярты шәһәрне каплап...
— Ә орденнары күпме! — ди, —
кителе генә кыска,
чак яшәсә булыр иде
генералиссимус та!
Сугышны полковник булып
бетергән кеше бит ул...
Эверест булып итенде...
Партия шеше бит ул...
— Үпкәләвең, үчең чыга...
— Синең чыкмас идеме?
Сиңа менә бу тормышның
хәтәр җиле тидеме?
Ә минем тормышымның ул
башын куйды аякка...
Партбилетны даулыйм икән —
даулыйм йөрәкне яклап,

чөнки аны берөзлексез
хаксызлык корты ашый...
Мин — НИИның якты башы —
селен барабан ташыйм
Казан хәтледән Ташкентка...
Күчтәнәч бирә-бирә...
Шушылай кимсетүләрнең
ну бер кирәген бирәм
әле...Исән генә булыйм —
Минаевтан* уздырып,
сатирик поэма язам,
сүзне утта кыздырып...

КамАЗның елына йөз мең
машина биргән чагы.
Рәис Беләй дан тавына
менә дә менә чабып —
инде Казаннан башлыклар
карый аңа баш чөеп...
Ләкин бик сирәкләр генә
үзеннән-үзе биек...
Матур бер кафега кердек,
утырдык бераз чәйләп,
конфет урнына Брежнев
дигән исемне чәйнәп.
Тәмсезләнеп бетә яздык...
Тизрәк юлга кузгалдык...

Абзый, оеп-оеп барып,
тәмле йокыга талды...

Йокласын йокы алганда...
Ә «Москвич» элдерә,
йә, чәчрәтеп, күлдәвеккә,
йә бозга барып керә.
Шыелдап уза «КамАЗ»лар
«Москвич» көзгесенә
чак-чак кына кагылмыйча...
Шул чакта йөрәк сеңә
умыртка баганасына,
күзеңә томан бага,
ә маңгайдан боздай суык
сыек куркыну ага.
Бу тар юлда кемнәр генә
шушындый тир түкмәгән —
аны «үлем юлы» диеп
әйтмиләр бит тикмәгә!
«Без татарга ярамаган
тагы!..» диеп уйлыйбыз —
башларны утка салачак
хәтәр белән уйныйбыз.
Үзебездә чыккан нефть
акчасына салганда,
ике тасмалы бу юлның
берсен генә алганнар,
янәсе ил мәнфәгате
татарныкыннан өстен!
Без, татарлар, әнә шулай
бик сознательный үстек.
Бакчы бу Нократ күперен!

Күперме инде шушы?!—
киң бөерле ике хатын
керсә — юл тыгылышы!..
Әнә Сон авылларының
күгәргән күрсәткече...
Кече Сон — музыкаль Мәккә
татар кешесе өчен —
өч Яруллинның нигезе!
Әллә кереп чыгасы?
Керерсең, бу юлсызлыкка
көпчәкләрең чыдаса...
Һичшиксез асфальт салырлар
анда, Кече Сонга да...
Татар бит әлегә тере,
үлгән генә соңгара...

Абзый киерелеп куйды:
— Ерак калдымы әле?
...Бит очлары алсуланган,
яхшырган иде хәле.
Аннары көлеп җибәрде:
— Бөтен эш минем кире —
кыз сорадык, ә кайтабыз
малайны кызга биреп.
Үзгәрә заман, үзгәрә —
җилләрен тоясыңмы?
Мин сизәм яңа заманга
үземнең сыймасымны.
— Һаман сөйләп бетермисең
Оренбурны... Сузасың...
— Аптыратма әле... Сөйләп
кәефемне бозасым
килеп тормый һич кенә дә...
Мин сөйләдем барын да...
Кыскасы, үз каным ага
улымның тамырында,
ул минеке, җиңгәгезнең
катнашы юк аңарга...
Бетте... Искә төшкән саен
үкенечләр яңара...
Беләсеңме, безнең якта
эшләр куера бара.
Башка әллә нинди шомнар
килеп китә кай ара.
Әйбәт яшәп калырыма
ышанычым аз анда...
Ташкентта дачаны сатып,
фатир алам Казанда —
төрле хәлләр булуы бар!..
Дәүләт тәгәри аска...
Генсек арты генсек үлә...
Фатир торсын запаста.

— Улың һәм киленең торыр, —
диеп, абзыйны хуплыйм.
— Запас фатир — минем өчен...
Син әйткәнчә... юк, булмый.
Кода бай да, булдыклы да —
ярдәм итсен, куансын...
Җиңгәң белән барып чыкмас...

Алданиләр буласын
Ходай гына белеп тора,
серләрен ләкин саклый...
Яшәүнең соңы билгеле,
ә Ходай язмыш яклы.
Ә язмыш һәрчак билгесез,
шуның белән кызык та.
Кеше Кеше булып атлый
иң ахыргы сызыкка.

...Абзый китте поезд белән —
самолетлар очмады...
Китте сүгә-сүгә өрек,
шәфталулар почмагын —
аны тартып тора торган
ямьнәр инде калмаган,
җанына башка омтылыш,
башка хис оялаган...

**10**

Абзый белеп, кода ул бай,
булдыклы, диеп әйтте.
Ай дигәндә яшьләргә ул
«азсемейка» юнәтте.
Нефтьчеләр аша, ахры...
Аларда дөнья башка,
чөнки нефть, акча булып,
агып тора тоташтан.
Ә акча кая китәдер?
Бер юлын әйтеп үтәм:
Әфган сугышы тәүлеккә
бер мильон доллар икән!..
Ярар, акча ага торсын...
Нишләр идек акмаса,
безнең тирән кесәбезгә
очып кереп капмаса,
колхоз фермасына чыпчык
кереп капкандай ялгыш?..
Акча турындагы уйлар —
сары берлектәй сагыш...

Яшьләрне «азсемейка»га
кода үзе күчерде.
Абзый тагы хаклы булды —
кода шатлык кичерде
яшьләргә ярдәм иткәнгә,
бәхет теләп һәм юрап...
Кода сүзгә саран иде,
күңеле ләкин юмарт.
Кичке ашка безгә килде
һәм бездә кунып китте...
Рюмкалап чәй эчә-эчә,
«теге» чакларга җиттек.
Телем сораудан кычытты,
ләкин мин кашымадым —
хәерлерәктер ачылмау!
«Мин кая ашыгамын?»
дигән уйларны тузгытып,
юкны аударып бушка

утырганда, кода әйтте:
— Без — күптәнге танышлар!
«Москва» кунакханәсендә
теге җиденче катта
сез әйбәт туры килдегез
минем күңелле чакка...
Әлмәттә үк, күргәчтен үк,
мин танып алдым сезне,
зур кайгыны шатлык белән
бозмыйча чак-чак түздем...

Хатыным табынга килсә,
кода тукталып тора,
һәм гаҗәеп оста итеп
сүзне башкага бора.
— Сөйләмәгәнсездер бит? — дип,
сорап куя... Күрәсең,
үзенең «батырлыклар»ын
килмидер белгертәсе
беркемгә, хәтта үзенә —
әнә уңайсызлана,
күзләрендә куркак нурлар
бер эри, бер бозлана...
— Әйе, сөйләгән идем,— дим, —
ләкин вакыт күп үтте...
Аннары сөйләгән идем,
билгесез кеше итеп...

Коданың күзләрендәге
борчылу тынычланды,
аның эзе, алсу таптай,
бит очларында калды...

Аһ, ирнең яшерен сере —
яшереп булмый торган
чәнечке ул — йөрәк итен
һәрвакыт тора тырнап.
Кайберәүләргә андый сер
яман чирдән дә яман,
кыска ялганыштагыдай,
бар нервылары яна.
Кайберәүләр андый серне
тотмый эчендә кысып,
алар өчен ул иң яхшы
мактаныч чыбыркысы —
болгап шартлатып җибәрә
кирәксә-кирәкмәсә,
Дон-Жуаннар данын эчә,
тутырып касә-касә...
Кода андый түгел иде...
Дуамаллык, җитдилек
аңарда яшиләр иде
чама белеп, чик белеп.
— Бәлки, сез мине әдәпсез,
бозык дип уйлагансыз...
Ләкин миндә үзегезне
күрергә кыймагансыз.
Ир кешенең йөрәгендә
иярләнгән ат ята,
дип әйтәләр... Мин килешмим —

бу әйтемдә бар хата.
Ир кешенең йөрәгендә
яши иярсез айгыр.
Шул айгырың кешнәмәсә,
эшләрең харап!.. Кайгыр,
чөнки син инде иреклек
тәмен тоймый башлаган,
һәм гомереңнең романы
кергән соңгы башламга.
Ә минем йөрәктәгесе,
иснәсә болын җилен,
иң-иң якты йолдызларны
күреп кайтырга тели...
Аның танавына сирәк
йолдызлар җиле бәрә...
Шул чакларда беравыкка
мин тезгенне җибәрәм.
Сызгыра җил, уйный, дулый
тузгыган ял кылында —
Җан җылына шул галәми
музыка ялкынында.
Тояклардан очкын оча,
якты төсләр көйрәтеп —
үзгәрә төнге күкнең дә,
күңелнең дә сурәте.
Тау очларына абынам,
диңгезләрдә чыланам...
Беләсезме, шул чакларда
әллә нишлим, чынланам,
үземнең асылымны мин
ачам, тирән төшенәм,
акыл арта... Мин әйләнәм
өр-яңа бер кешегә.
Баш югалткан мизгел белән
акыл җыйган мизгелнең
бергә туры килгән чагы
беркайчан да сизелми...
Сез менә туры килдегез
нәкъ шушындый чагыма —
үзем теләп бии идем
мин хәтәр пычагында.
Ничек беттеме?.. О! Ул сез
уйлаганча бетмәде...
Алар алдында үземне
бер дә ким-хур итмәдем —
йөзәр сум акча кыстырдым
һәркайсы изүенә,
шылтыр иснәп исермәдем!
Бу мине бизи генә!..
Һәм кода табынга Тукай
шигырьләрен ташлады:
«Мин дә шуннан бирле андый
эшкә кыймый башладым...»
Ләкин башка очракларда
башкача тәвәккәллек
кирәк булса, ни эшлисен
бүгенгә булмый белеп...

Кода үзенчә философ,
психолог булып чыкты —

фикере нинди шәрехле,
сүзләре нинди чуклы!..
Ияр...Айгыр... Баш югалткан
һәм акыл җыйган мизгел...
Бу фәлсәфә аны түгел,
хәтта шагыйрьне бизи
алыр иде... Ләкин шагыйрь
гаҗәеп татарчалап,
башка тирәнлекне буйлый:
без — яхшы, алар — начар...

— Ярар,— димен,— кабул итик
«айгыр теориясен»...
Ә хатын-кыз йөрәгендә
ятса нәсел биясе?
Биянең дә танавына
болын исләре керә,
ә күзләре йолдызларның
тылсымлы нурын күрә...
— Нинди бия, нинди йөрәк,
нинди бәхәс табында? —
диеп, безнең әңгәмәгә
кушылды хатыным да.
— Ир йөрәгендә ат була —
моны белә һәркем дә.
Нәрсә ята икән, дибез
хатын-кыз йөрәгендә...
Һәм хатыным туктап калды.
Кабырганың хушисе,
борынны кытыклап үтеп,
безнең карынны кисте.
Бик тәмле пешерә иде
кабырга дигән сыйны!
Ул сыйның бөтен серләрен
сөйләп торырга кыймыйм —
аңа үз исемен биреп,
җибәрмәкче Парижга...
Биш-алты ел кыстыйм инде,
ул җибәрми, карыша,
рецепт белән һич булмый, ди,
бернәрсә дә пешереп...
Юныс Әхмәтҗан* китабын,
яле, искә төшерик:
әйтик, талкыш кәләвәне
андагы ысул белән
пешерә алган кешене
бер Ходай гына белә...
— Кабырга капмаган килеш
йоттың мәллә телеңне?
— Юк ла, сорау бик катлаулы —
мең җавапка бүленде...
Хатын-кызның йөрәгендә
биләүле бала ята.
Биләүле бала янында
була иярле ат та —
сезнең кебек ир-егетләр
дөнья гизсеннәр өчен,
үзләрен фәрештә кебек
азат сизсеннәр өчен...
— Вот, ичмаса, акыллы сүз —

давай шуның өчен,— дип,
рюмкаларга койды кода
сүз раслаучы эчемлек...
(«Сүз раслаучы» — аракының
тагын да бер титулы...
Россиядә бу эчемлек
иксез-чиксез сер тулы...)
Һәм кода эчеп тә куйды.
Ул шундый горур иде —
хаклыкка һәйкәл койсалар,
натурщик булыр иде.
Ә хатыным дәвам итте:
— Түзем кирәк әз генә —
ләкин биләүгә бәйләнгән
иярле ат тезгене...
Чишелми дә, өзелми дә —
ул тезген әнә шундый...

Кода башын чайкап куйды:
— Бусы да аңлашылды...

**11**

Безнең якта иң гүзәл ай,
мөгаен, сентябрьдер —
яз һәм җәйнең яшеленә
төрле төсмерләр керер.
Һәр агачның һәр яфрагын,
күлмәк төсенә карап,
буладыр затлы, килешле
брошка итеп кадап.
Җәй гөлләре әле исән...
Көз гөлләре дә, балкып,
мең төс белән залп бирә,
куркытып болыт халкын.
Тарала авыр болытлар,
көз гөлләрен чылатып...
Җитә әбиләр чуагы,
сокландырып, җылатып,
сагындырып үткәндәге
иң романтик хәлләрне...
Сентябрь ул ел-тәүлекнең
соңгы җылы хәбәре.

Бөтен кайгы, мәшәкатьне
беразга оныттырып,
нәкъ әбиләр чуагында
абзыйга онык туды.
Әлмәткә дә, Ташкентка да
хәбәр очты кичекми...
Шул ук төнне Әлмәт кода
какты безнең ишекне,
әлбәттә, кодагый белән...
Килеп керә-керешли
шампан шәрабы аттырды:
— Бу нәрсәсез килешми
матур хәбәр биргән йортның
ишекләрен ачу да! —
Тизрәк фужер китерегез,
күрәсез, качып чыга
шешәдә йоклаган шатлык...

Менә шулай...
— Тамызма...
Ходай гел шәраб агызсын
тәмле сүзле авызга!
(Менә шәрабның тагын бер
титулы яңгырады —
соңгысы түгел, әлбәттә...
Күбесе әле калды!)
— Хуш киләсез, чишенегез,
әйдә, түрдән узыгыз!
— Нинди узу?! Кайда ята
бәбкәчебез-кызыбыз?
Барып кайтыйк...
— Ашыкмагыз,
кемне диеп сорагыз...
— Сорамыйча да билгеле —
малай диеп торабыз! —
улыбызны әнә алды...
Юлы юк аның башка —
малай җибәрергә тиеш
урынына, алмашка...
Һәм кода дөресен әйтте...
Табигатьме, Аллаһмы —
кешегә бурычын түли,
беркайчан да алдамый.
Ә кеше... тирән кесәле,
ач күзле һәм зур учлы —
тартып ала, урлый, яулый...
һәм кайтармый бурычын
Аллаһка да, муллага да,
җиргә-суга да хәтта,
табигать ул җүләр, диеп,
күккә төкереп ята.
Ә табигать җүләр түгел!
Ә табигать үч туплый!..
Белмим, алда ниләр көтә
без мактанчык-ычтыкны...

Кодаларның куанычын
булмас сөйләп бетереп...
Ә абзыйдан хәбәр никтер
шактый озак көттерде.
Алдан килде телеграмма...
бары үзе исменнән.
Язылган иде ул котлау,
шагыйранә хис белән.
Русча язылган робагый
бик тә тәэсирле иде —
хатынымның йөрәгенең
күзенә барып тиде.
— Менә бит настоящий ир!..
менә бит алар нинди!
Син роддомга өч канәфер
чәчәге алып килдең —
кабер өстенә, ирләргә
куела торганнарны... —
диеп, хатыным тузгытты
хурлану бураннары...
— Һәйкәлләргә дә куела
кып-кызыл канәферләр! —

диеп, мин дә тарткалаштым —
кимен куймадым бер дә,—
Малай тапкач, син бит миңа
күрендең һәйкәл булып...
...Ә хатын үкерә бирде,
робагыйдан буылып...

Әй, Шигырь! Җыр! Әй, Җылы Сүз!
Туң, таш дөнья аша сез
җан үзәген табып ничек
канына тоташасыз?!
Күздә, эчтә тыгылышкан
яшь чишмәләрен ничек
ачып җибәрә аласыз,
туң, таш күңелләр кичеп?!
Ничек шул күз яшьләренә
йә бал, йә тоз өстисез?!
Әй, Шигырь! Җыр! Әй, Җылы Сүз!
Аллаһ сүзе төсле сез!!!

Шулай итеп, көтмәгәндә
минем гаиләнең дә
чаршавы ачылып китте
хатын җилфердәвеннән.
Кызыбыз бар, улыбыз бар —
мәктәп укучылары...
Аларны телгә алырлык
җай романда чыгармы? —
әлегә үзем дә белмим.
Бүген әле кирәкми —
җил белән терәтү нигә
төзек үскән тирәкне?!
Алардан герой эзләмим...
Алда вакытлары бар,
лаек булсалар, аларны
чын әдип эзләп табар —
үз заманнары Байроны,
Пушкины, Лермонтовы...
Мин балаларым чорыннан,
табигый, алда тудым...

...Өч-дүрт атна вакыт үткәч,
абзый да килеп төште —
Ташкент түгел, Оренбурдан...
Шул инде — теге эштер...
Өйгә керә-керешли үк,
чишенеп тә тормады,
әллә нинди посылкалар
килдеме, дип сорады.
Юк, килмәде әле, дигәч,
абзый дөньясын киде...
Күрәсең, нервы җепләре
сүсәреп беткән иде.
Күзләрен каплаган иде
кырау кунган кашлары...
Телеграммам өчен мине
селеккәләп ташлады:
— Телеграм шундый буламы? —
поздравляю родила...
Родила кызмы, малаймы?

Елки-палки... Вот дела...
Нинди кием алырга да
белми йөрдем аптырап...
Оныкның тәпиен юыйк —
сал, авыз ачып торма!..

Портфеленнән алып сузды
кара этикеткалы
«Дипломат» дигән аракы...
Ничек тапкандыр аны?!
Бездә ул — затлы дефицит...
Төньяк котыпта карның,
Сахара чүлендә комның
дефицит чагы бармы?!
Ә бездә менә дефицит...
Хәтта мунча ташыннан
самогон кайнаткан илдә!..
Тай типкәндер башына...
Фин кәгазе түземле ич,
рус хәйләсенә чыдар —
бер мичкәдән унбер төрле
«затлы» аракы чыгар,
бәясен бераз арттыр да,
сат әйдә, рәхәтләндер —
бәя зәһәрләнгән саен,
бездә аракы тәмле...

Борып шыртлаттык бөкесен
Ташкент «Дипломат»ының.
Җылытып тормыйча гына
сумса бирде хатыным,
чөнки абзыйның түземе
кайный башлаган иде...
Аның нервылары инде
шактый какшаган иде,
гәрчә соңгы елларында
ул өзлексез «чыныкты»...
— Әйтегез, кызмы, малаймы,
в конце концов, оныгым?
— Малай! — дидек бертавыштан...
— Имәме?.. Сөте бармы?..
— Имә! Тәүлек буе имә,
авызы бер дә армый —
нәкъ менә синеке кебек...
Үскәч хәтта арттырыр —
мәзәкче артист булыр, йә
футбол комментаторы.

Абзый шат! Көлә ул кешнәп,
йөрәк белән йөткереп:
— Теле йөгерек кешенең
акылы да йөгерек —
мин аны, исәнлек булса,
беләсезме, кем итәм?
Дипломат!.. Һәм аның белән
берәр чит илгә китәм —
көчле партия башында
яшь кеше торган илгә...
— Шулай, аптыраган үрдәк
арт белән чума күлгә...

Җүләр сүз сөйләмә әле...
Әйдә, акылыңа кайт —
дипломатлыгыңны йотты
шешәдәге «Дипломат»...
Чит-ятка сөйләнә күрмә,
хәлең болай да хөрти, —
дип, хатыным абзыкайның
шешле төшенә төртте.
Ыңгырашып куйды абзый...
Һәм телен тешли алды...
Улын, оныгын күрергә
ул көнне бармый калды.

Иртәгәсен анда китте
юынып-тазарынып...
Бөтен авыр уйларыннан,
хисләреннән арынып.

...Һәм соңыннан сөйләделәр:
ул, оныгын кочаклап,
бераз торган, аны куйган,
борылган да почмакка,
елап җибәргән тавышсыз...
Талган иңнәре генә
тетрәп торган, йөрәгенең
сулкылдап бәрүеннән.
Коточкыч озак елаган.
Яшьләр курка калганнар —
аларның җаны айкалган
чап-чал баш чайкалганда...

...Абзый төнлә генә кайтты
октябрьгә чыланып...
Татлы уйлар дөньясыннан
һич бирегә чыгалмый.
Башы горур! Күзләрдә нур!
Йөзе — тылсымлы бизәк...
Иреннәре — алсу каек,
Кәүсәр суында йөзә...
Күзеннән төшкән яктылык
иреннәрендә уйный...
Йа Хода, килгән диярсең
чын Будда Шакья-Муни!..*
Өстәл янына утырды.
Тынычлык — кыяфәте.
Тынычлык ул куанычның
иң югары халәте.
Кичәдән калган шешәне
өстәл түренә куйдым...
Ни сәбәптер, абзыйкайны
кыстарга һич тә кыймыйм —
күңел тартмый, тел әйләнми,
чөнки... ничек дип әйтим...
абзыйдан бөркелә иде
изгелек галәмәте.
— Юк, кирәкми,— диде абзый, —
бәгырь сыегаймасын,
оныгым биргән хисләрне
акылым да аңласын.
Бүтән чыгарма шешәңне —

кирәге бетте, капмыйм,
онытым сеңде җаныма —
пәйгамбәр кебек пакь мин.
Аңлыйсызмы — мин дәвамлы?!
Үз балаң — өмет бары.
Ә менә балаң баласын
дәвам дисәң дә ярый!
Балалар китабы язам...
Шәт, басылып та чыгар...
Успенский гына мәллә
бу илдә язучылар?!
Сездә, татарда, бармы соң
Михалковлар, Бартолар?
— Ничек диеп әйтим инде —
язучылар... бар алар,
ләкин педагог-шагыйрьләр...
бик аз алар... аз алар.
Балалар сөйләмен алып,
мәзәк итеп язалар.
Андый шигырьләрне уку
өлкәннәр өчен кызык,
ә баланың күңеленә
кагылмый, китә узып...
— Әгәр сүзең дөрес булса,
татар балаларының
эшләре шәптән түгел,— дип,
абзабыз калды тынып...

Ә абзый дачасын саткан...
Аһ, шәп иде дачасы —
өч-дүрт төрле йөзем иде,
груша, алычасы,
алма, өрек һәм абрикос,
чия, төче чиясе...
Һәрхәлдә, бик канәгатьтер
аның яңа иясе.
Йөзем аллеясы буйлап,
биектә, рельслардан
бер тәлгәштән бер тәлгәшкә
тәгәри иде арба.
Өе силикат кирпечтән,
кыегы биек иде.
Бик иркен чарлак ясалган
безнең як өе иде.
Бәләкәй генә мунчасы
электр сауналы.
Чабынып бер басар өчен
Казанны сагынганын...
Барысын сатып җибәргән
шактый юмарт яһүдкә...
Акча бар — ике бүлмәле
фатир алырга җиткән...

Абзый шушы килүендә
җайлады бу эшне дә...
Ахры, Ходай юнен бирә
җаны юньле кешегә.
Дачасын алган яһүднең
кемедер монда киткән,
кайсыдыр кооперативта

рәислек итә икән.
Шуның аркылы бер картның
фатирын килешкәннәр...
Ә дөресе — юнен бирә
«садака» бүлешкәнгә...

Күтәренке күңел белән
китте абзый бу юлы.
Чарасызлык, төшенкелек
калды монда коелып.
Ул киткәч, атна ярымнан
ике посылка килде —
берсендә бала киеме,
берсендә җимеш иде.
Абзыйдан хат килеп төште.
Ул шуны бәян иткән:
посылкалар Россиягә
бик авыр китә икән...

**12**

Март кояшы түбәләргә
сак бозбармаклар элде...
Сталиннан үрнәк алып,
тагын бер Генсек үлде...
Халыкка мөрәҗәгатьләр,
пленумнар да узды.
Рим папалары сайланган
сәер гадәтне бозып,
тиздән үләчәк бер картны
сайламыйча, бу юлы
яшь Генсек сайлап куйдылар.
Заманча һәм нык куллы
бу лидер тончыккан илне
саф һавалы дөньяга
алып чыгар һичшиксез, дип,
без шатландык бик яман —
Аллаһның кашка тәкәсен
очраткан кебек булдык...
Шикләрне читкә этәреп,
безгә ышаныч тулды.

Фатирын карап торуны
безгә йөкләде абзый:
трубасы шартламаганмы?
чыгып тормыймы газы?
тәрәзен ватмаганнармы?
кермәгәнме караклар?..
Кимендә атнасына бер
кайткалыйбыз караклап.
Карттан калган суыткычны
токтан өздек — белмәссең...
Ачып, эчен җиллләтәбез —
һавасы сөрсемәсен.
Пианиносын да алган...
Нигә инде анысы?
Үзе гитарада уйный...
Уйный болай ярыйсы.

Пианино эчләренә

су куябыз — кипмәсен!..
Өй тузанын суыртабыз —
килгәч, иза чикмәсен...

Йа Россия фатирлары!
Караватъ белән диван
кайсы өйдә бер бүлмәгә
икесе бергә сыйган?!
Йа Россия осталары!
Даһилык сездә тере —
сыйдырасыз караватъ һәм
диванны берләштереп.
Йа Россия тәрәзләре!
Сөенечкә тоташлар:
ача алсаң, яба алсаң —
бәхетең чиктин аша.
Йа Россия ишекләре! —
картон белән җилемнән,
шыгырдыйлар, ә аумыйлар
җитез итәк җиленнән.
Йа Россия ванныйлары! —
әбрәкәйгә кушылган.
Илнең яшәү җайлылыгы
башланадыр шушыннан.
Йа Россия төзелеше!
Кем өчен син, кем өчен?..
Фатирда шатлык урнына
кешенең үкенече...

Ә яшьләр «азсемейка»да
яшәп яталар гөрләп —
яшь әти көндез укуда.
Ул кичке эшкә кергән.
Яшь ана — академ-ялда...
Һәм аның төп шөгыле...
язмыйча, сөйләмичә дә
һәр кешегә билгеле.
Ай саен бер-ике тапкыр
килеп китә әлмәтләр,
яшьләрнең матди хәлләрен
нефтьчеләрчә рәтләп.
Көне буе булалар да
кияве-кызларында,
кунакханәгә китәләр...
Безне тыгызламыйлар.
Безгә дә кереп чыгалар —
чәй чәйләп утырабыз...
Кагылмыйбыз Мәскәүдәге
«авырткан кутырга» без.
Ул мактый яңа Генсекны:
— Буласының... күренә,
тикмәгә тамга сукмаган
аның маңгай түренә...
Урамнарда ничек йөри —
һич курыкмый халыктан.
Бусы — тегеләре түгел,
бусы — башка калыптан!..

Ил белән идарә итү
халыктан курка-курка,

Россия сәясәтендә
мәңге йөзүче турта.
Ничә патша үтерелде...
Ленинга да аттылар...
Һәм генсеклар Кремльдә
шуңа посып яттылар.
Хакимият белән халык
безнең илдә — дошманнар...
Аралыкта — иң агулы
гөмбә кебек — куштаннар...

Чү! Мин дә бит гомер буе
яшәдем аралыкта!..
Җанымның ике ягын да
яман яралар ерткан.
Власть ягы яраларын
чиктән тыш оятсызлык
тирән уйган. Һәм ул яра
аңымны айкап сызлый.
Халык ягы яраларын
сарыклык, чарасызлык
ярып салган. Һәм ул яра
җелеккә җитеп сызлый.
Яраклашмадым халыкка,
чөнки мөмкин түгел эш,
чөнки меңне сыйдыралмый
меңнән алган бер өлеш.
Тамчыда диңгез чагыла,
дип әйтәләр... Ә давыл,
ә корабларны урталай
сындырган дулкын тавы
кайсы төшендә тамчының
саклана, чыга алмый?
Тамчыда диңгезне диңгез
иткән нәрсә чагылмый.
Ә кеше — халык тамчысы,
ә халык диңгез ише...
Кешедә халык чагылмый,
з а м а н боза кешене!
Елышмадым мин властька
намус бәрабәренә,
гәрчә кагылгаласам да
хакимнәр мөнбәренә.
Ялагайлана алмадым —
горурлык Алыпныкы,
акылым үземнеке һәм
йөрәгем халыкныкы...

...Мин дә кодага кушылам:
— Кеше язганны гына
укып йөрми — сүзе шуңа
йөрәккә килеп куна.
...Кода кашларын җыера:
— Ләкин менә хатынын
нигә ияртеп йөри ул?
Әллә сүзе алтынмы?..
— Философия фәннәре
кандидаты... Чибәр дә...
Күрәсең, ире фикерен

дөрес юлдан җибәрә...
— Юк, килешмим, Генсек бит ул,
Генеральный секретарь!..
Ярый, әйтик, чит илләргә,
тели икән, тагып бар...
Ярдәм итә алса, итсен...
Чит илләрдә — катлаулы...
СССР буйлап йөргәндә,
авыр мәллә атлавы?!
Әллә, мин әйтәм, хатынсыз
бер төн дә түзми торган
секс-бомбамы партия
тәхетенә утырган?..

Агарынды минем хатын...
Күз төпләре караңгы.
Сикереп торды кодагый,
як-ягына каранды:
— Тиле, син нәрсә сөйлисең?
Рюмка сөйләтә, дисәң,
рюмка да юк... Телең безнең
башны бетерә, исәр...
— Бетерми! Заман үзгәрде —
демократия килә,
үлгән генсеклар турында
тозлы мәзәкләр сөйләп...
Кодагый янә кушылды...
Ул җаен таба белә:
— Юләр сүзләр сөйләгәнче,
син малай хәлен сөйлә...
Аның һәлак булган көнен
мәктәп билгеләп үтте,
исемен мәңгеләштереп,
карар да кабул итте:
комсомол оешмасының
исемлегенә аның
исемен теркәргә, диеп...
— Әйбәт булган дип саныйм...
— Бик тә тантаналы булды.
Укыдык соңгы хатын...
Күз яшенә бата-бата,
елады күпме хатын.
Кайберләренең уллары
армиядә хезмәттә...
Тик хатлары, сирәк килеп,
йөрәкләрен йөдәтә.
Безнекенең дә хатлары
озак Куйбыштан килде...
Әфганда икәнен аның
сүз арасыннан белдек.
Ә соңгы хатларын балам
ачыктан-ачык язды:
Чарикара тирәсендә
тау-ташта окоп казыйм...
— Иң соңгы хатында язган
бик күп өрәк урдым, дип,
шуның өчен тапшыралар
Кызыл Йолдыз ордены...
— Белмим, ул орден каядыр?
Хәер, безгә нигә ул?..

Канаты белән хурлыклы
җиңелүгә тигән ул...
— Кайчан бетәр бу суешу?
— Бик тиз бетмәс — кирәк ул,
анда бит корал сынала —
Ватаныбыз терәге.
Сугыш ул бөтен кешенең
аңын төпли бер төпкә,
башкасын уйлап торырга
көче калмый бөртек тә...
Беләсеңме, без, асылда,
торгынлыкка тарганбыз —
алга! дибез, алга! дибез,
артка таба барабыз...

Озакка сузыла чәйләр...
Чәйләр суынып бетә...
Кызганнан, кыза әңгәмә,
телләрне өтә-өтә.
Куныгыз, диеп кыстыйбыз...
Алар, гадәттәгечә,
кунакханәгә китәләр...
Өзелә кайнар кичә...

**13**

Елына ике мәртәбә
селен барабан ташып,
абзый әллә кемнәр белән
Казанда хәзер таныш.
Аларга китерә торды
шәмәхә чәйнек, касә —
бераз эшне тизләтергә,
борчу-мазар белмәскә...
Бара-бара барып җиткән
ул партком тирәсенә —
завод парткомының шактый
югары түрәсенә...
Шуның юбилее икән!
Абзый Казанда тагын...
Алмагачлар салютының
җиргә сибелгән чагы.
Абзый килеп төшкән көнне
илгә хәбәр таралды:
эчкечелекне чабарга
партия чалгы алды!
Алкоголизм үләнен
йолкый-йолкый арытты,
хәзер чабып ыргытабыз
бу агулы сарутны!
Бәйрәмнәр, туйлар бүгеннән
узарлар аракысыз.
Партгөнаһ дип саналачак
шушы карарны бозу.
Үзенә көчләп тагылган
чирдән Россия — гарык...
Партноменклатура үзе
үрнәк булыр, юл ярыр!..

Авыр урнаша һәр илдә

яңа уй, яңа тәртип —
бүген-иртәгә дөньябыз
искечә тәгәрәр, дип,
сөйләштек без абзый белән,
пәрдәләрне яптык та,
«Соңгы тапкыр булса — жәл!..» — дип,
йөзәр грамм каптык та...
Аракы, һич булмаганча,
тоелды тәмле булып.
Тәнгә агылды җылылык,
ә аңга — якты болыт.
Ул болыттан яуды телгә
һич көтмәгән аеклык.
— Аракы диңгезен эчеп,
илнең аңы саекты,
чөнки без эчә белмибез,
культурный дип йөрсәк тә —
Шукшин фильмын искә төшер,
Шукшин дөрес күрсәтә:
бит «Наполеон» коньягын
тустаганлап, мунчада
эчәбез селедка кабып...
Шаккатып, җен бот чаба...
— Ләкин нәтиҗә бирерме
карарлап кысу гына?
— Юкса Россия үләчәк
буылып косыгына...
Чираттагы бер кампанья
булып калуы мөмкин...
Россиядә һәрбер эштә
табылачак Потемкин*...
Кампаньяләрнең уңышлы
беткәннәре юк иде...
— Кызык, ничек узар икән
син барасы юбилей?..
— Ничек үтсен? Әйбәт үтәр,
менә сынап карарсың —
СССРда озын була
сүз белән эш арасы.

Алма бакчалары Җирдә
иң гүзәл бизәк иде.
Ай белән кояш күренеп,
парлашып йөзә иде.
Шомырт суыклары никтер
артык сузылган иде...
Тормыш механикасында
нидер бозылган иде.
Юбилейда дип уйлаган
абзабыз тиздән кайтты.
«Умора, брат, умора!..»
диеп, күзен акайтты.
Мәҗлес булмый калган икән...
Ресторан хезмәткәре
барчасын, гафу үтенеп,
борып җибәргән кире —
юбилярга нидер булган,
ни булганын кем белә?..
Беркем дә үз юбилеен
өзмидер үзе теләп...

— Умора, брат, умора,
исең-һушың китәрлек —
Ташкенттан килгән сервизны
йөрим менә күтәреп...
Өйләренә барам хәзер.
Өйдә булса, котлармын...
Шул, ЦеКаның карарыннан
очкан аның котлары!
Бигрәк куркак кеше инде —
шүрли үз шәүләсеннән —
утыз җиденченең җиле
аңа да тирән сеңгән...
Пенсиягә китмәс әле —
авторитеты олы,
торыр шунда директорда
берәр консультант булып...

Абзый китте...Һәм кайтмады —
кунгандыр үз өендә.
Ул күптәннән яши иде
үз җаена-көенә.

Соңгы өч ел дәверендә,
болганып киткәч эше,
ыгы-зыгыга әйләнде
аның яшәү рәвеше.
Шагыйрьлеген күмеп китте
әллә нинди мәшәкать...
Кешене вак мәшәкатьләр
фанилыкта яшәтә.
Ирек бирми чиксез җанга
керләнеп беткән тәнен
беразга салып торырга
һәм кияргә бүтәнне —
галимнекен, хакимнекен,
сандугач, баланныкын,
гүзәл хатын күкрәгенә
баш төрткән баланыкын,
берәр ил башлыгыныкын
йә роза гөленекен...
Күзең йом, кеше, хыяллан!
Күзең ач, кеше, үкен!..

Җәйге аландай күңелен
аның нидер җәберли...
Юк, партбилет кына түгел,
тагын нидер җай бирми
тирән күл кебек тынарга —
һаман, һаман болгана.
Хистән бүртенгән йөрәккә
озак тулгану яман.
Нәрсәдер эшлисе килә,
ләкин никтер эшләми,
нинедер тешлисе килә,
ни сәбәптер — тешләми.
Сугарга дип йодрык чөя...
Туктый... Кашый лепкәсен...
Эчтән генә, тешне кысып,
тетә язмыш тетмәсен.
Үзе — кайнап шарты килгән

көнбагыш мае сыман —
тыштан тыныч, ә тирәндә
эретә кавырсынны.

Шул кайнарлыкта үзе дә
көя иде, бахырың...
Хәерлегә генә булсын
көюләрнең ахыры.

Кайттым эштән... Һәм белештем —
абзый безгә килмәгән...
Булып куя күрмәсен, дип,
чүп өстенә чүмәлә,
мин фатирына ашыктым...
Ул соңгы вакытларда
йөрәккә зарлана иде.
Аннары яшә каргап
үзеңне-үзең гомергә,
әллә ни булып куйса...
Үземнең дә күкрәк туры
сул яктан бераз кыса...

Абзый өйдә. Өстәлендә
алты-җиде бит кәгазь...
— Менә тырмаштырам әле
башка килгәнне аз-маз...
Безнең илдә бүген мәзәк
тоелган эш иртәгә,
сатира айгыры булып,
дулап тибә тәртәгә.
Әнә «Правда»ны укы,
аның баш мәкаләсен —
«Трезвость — норма жизни»* дигән...
Тукта, нигә көләсең?
Син әүвәле укы әле...
Эшләр куера харап —
ил Генсек маңгаендагы
э-тап-ка кереп бара.

Аракы, вино чөмереп,
кыланды эте-бете...
Кызмача туй уздырулар
июньнән башлап бетә,
бетә иртәнге сигездән
йөгерү аракыга —
кысыла сату вакыты,
мөһиме — талон чыга!..

— Алда хәлләр көтә икән...
Күрдеңме юбилярны? —
валлаһи, дим, аның өчен
минем дә йөрәк әрни...
— Күрдем, күрдем — өйдә иде.
Матур дастархан корган,
хатыны белән икәүләп,
мәҗлес корып утыра.
Мине күргәч куандылар:
ник бер юньсезе килсен —
түрдән уз! дип күрсәттеләр
иң зур хөрмәт билгесе.

Менә беренче юньсезе,—
мин әйтәм,— килеп җитте...
Хатыны елап җибәрде
тетрәтеп ирен читен.
— Үпкәләттең, куркак куян,
шушындый юлга басып.
Үткәреп калган булсак та,
куймаслар иде асып,—
ди хатыны... Ә тегесе:
— Илкүләм гыйбрәт итеп,
карточкага парт-выговор
куячаклар беркетеп,
эштән селтәп атачаклар —
булачак сабак адым... —
бит беркем дә үз өстенә
җаваплылык алмады:
ни парткомы, ни райкомы,
ни горкомы, ни обком!
Кыскасы, дөрес эшләдем,
килешәм — син дә хаклы.
— Китәр идең пенсиягә,
эшләренә төкереп...
Болай әнә дусларыңны
үпкәләтеп бетердең,—
дип, ялкынга давыл өсти
тәмам борчылган хатын...
— Дуслар... табылыр... Бүген мин
партия белән атлыйм...
Менә килде бит...Ташкенттан! —
ташла үпкәңне, оныт...
...Кыскасы, өчәү утырдык
өй тулы кунак булып.
Телефон чылтырап торды.
Алды хатыны гына,
ирен чакырмады, сылтап
кәефе юклыгына...

...Ым кагам кәгазьләренә:
— Ничек, язып буламы?
— Нәрсә әйтим? — фикер, хисләр
очмый әле, дуламый...
Акыл теле бик авырдан
хәрәкәтләнә әле —
сүзләр уй булып тезелми,
таба алмый әмәлен.
Бик озак язмый тордым бит —
күгәрде тел күчәре...
Иҗатка тышавын сала
җанның ачу-үчләре.
Уйга, тупланып, үз-үзен
сүзләргә төрә-төрә,
шигырьгә әйләнер өчен
җан тынычлыгы кирәк!
Җан тынычлыгы дигәнең
бармы соң миндә? Кайда?
Кай тарафларга очса да,
җан давыл тулып кайта.
— Син, абзый, үзеңне-үзең
үзәктән болгатасың
һәм болганган үзегеңә

күздән тикле баткансың.
Бу дөньяда партбилетсыз
яшәүче син генәме?!
Бик беләсең килсә, халык
билетлыны өнәми.
Җаны чакырганга түгел,
хәйләсе төртә-төртә,
партиягә кергән меңнәр
аның билетын йөртә.
— Партиядән куылганны
халык, үземнән беләм,
иске палас итеп таптап,
койма башына элә...
— Хатыннан уңмадың икән...
андыйлар дөнья тулы,
ләкин беркем дә яшәми
уфтану колы булып.
Уйларга ышкып, йөрәкне
ут капканчы кыздыру
неандертальләр ысулын
вәхшиләрчә уздыру,
дигән уй синең башыңа
кереп чыкмыймы бер дә?..
— Керә... Ләкин чыга алмый,
әйләнә бара чиргә...
— Соң, тәвәккәллә булмаса —
кор яңабаштан оя —
чын мөселман кочагына
дүрткәчә хатын сыя...
— Котыртма, брат, котыртма,
мин болай да котырган...
Әйтсәм әйтим... Мин Мәскәүдән
хәбәр көтеп утырам —
сезнең яңа ж и ң г ә г е з д ә н...

...Менә сиңа чикләвек!
Юк, абзабыз утырмаган
кәлҗемә кебек җебеп...
Юк, батмаган ул үзенең
болганчык үзәгенә —
чарасыз бер кеше булып
күренгән күзгә генә...
Абзый бик җитди эшләрен
эшли иде астыртын...
Куен кесәсенә кереп,
алып чыкты паспортын,
шалт итеп өстәлгә салды:
— Ачып штампын кара —
гомеремдә мин тагын бер
тәвәккәллеккә барам...

Оренбур, Җаек якларын
абзыйның еш иңләве
әнә ни сәбәптән икән!..
Һәм без яңа җиңгәле...
— Нинди кеше? Ничә яшьтә?
Бармы бала-чагасы?
— Бер улы бар...Үзе татар...
Яшькә?.. Сезнең чамасы...
Ярар, бик аптыратмагыз...

Әлегә җитеп торыр...
Исән булсак, бик тә тиздән
каршыгызда утырыр...
— Мәскәүдә ни эшләр кыра?
— Ни кыра? — мине аклый —
менә инде ике атна
ЦеКа юлларын таптый...
— Яңа җиңги хәтәр икән —
Ленин әнисе кебек —
улы Сашаны үлемнән
йолып калырга теләп,
хәтта патшага кергән бит,
каушап калмаган һич тә...
— Бик мәйле!.. Юньле хатынны
төшергән җиңгәң искә...
Абынган атның аягын
тышауларга тырышу,
егылып китсен, кадалсын,
диеп шуңа булышу
нәрсәне искә төшерә?..
Ә... белемегез тармы? —
абынганны егылырга
этәрү ул — татарлык!
Бу — сезнең Ташкент җиңгәгез!
Андыйлар дөнья тулы —
йөриләр тирә-юнеңдә
изге фәрештә булып.

Абзый алды телеграмма —
өсте кызыл тасмалы.
Шатлыгыннан очып йөрде
абзый, җиргә басмады.

Күңеленә өмет керсә,
күзләр зурая икән —
кәкре үскән агачлар да
кинәт турая икән.
Өмет тавышын ишетсә,
колаклар тона икән —
шик-шөбһәләр пышылдавын
ишетми шуңа икән.
Өмет һавасын суласаң,
телләр баллана икән —
бөек шагыйрьләр теленә
барып ялгана икән!..

Хәбәр итте Ташкентына
ЦеКага чакыртуны.
Күзләрендә кыю балкыш,
йөрәге өмет тулы...

**14**

Иртәгә китәсе кичне,
минут та калмый соңга,
нәкъ җидедә җыелыштык
абзый «конурасы»нда.
Конурада этләр яши,
дигән идем берсендә,
абзый каты җавап бирде:

— Мин дә эт типкесендә...
Ярар, «конура» булсын ди...
Абзый пылау пешергән.
Астын өскә әйләндерде
һәм пылавын төшерде
иркен поднос уртасына...
Һәм салдырды казанын...
Тукта, ашказанын үртәп,
нигә әле язамын
пылауның хасиятләрен,
аның тәмле тау булып
табынны ямьләп торуын?..
Сагынып, ахры, сагынып...
Ә сагынырлык берни дә
булмады бит ул кичтә...
Киресенчә, үлә яздык
ул кичтә авыр хистән...
Тезелешеп, өч гаилә
утырабыз гөрләшеп,
күз аша пылауга баккан
карын белән көрәшеп.
Пылауның чыны турында
ул матур сөйли белә —
сүзеннән майлар агызып,
абзабыз пылау бүлә:
хатыныма салды, миңа,
килененә, улына...
Һәм тугыз айлык оныгын
утыртып сул кулына,
нарасый булып сөйләнде:
— Менә бусы үземә,
чөнки бусында йөзем күп,
мин яратам йөземне;
ә бусы дәү әтиемә,
чөнки ите сөякле;
бу тәлинкә чиста калыр,
аңа берни эләкми,
чөнки дәү әниебез юк,
бәлки, булыр да тиздән...
...Шунда улы торып басты,
күзе әтисен сөзә:
— Ничек дәү әниебез юк? —
минем әни кем аңа?..
...Табынга тынлык капланды,
пылау исен томалап.
Улы сабыйга сузылды.
Абзый этәрде кулын.
Гаҗәп! Абзый каушамады,
тыныч иде бу юлы.
Бу — аның инде күптәннән
әйтәсе килгән сүзен
башлавы иде үзенчә,
чөнки бик озак түзде,
бик озак китерде җаен...
Күрәсең, уйлап тапты.
Һәм тәмле пылауга кушып
без аның сүзен каптык.
— Улым, син токсыз рубильник,
күзле бүкән түгелсең —
гаилә давылын сезгә

сөйләп тору күңелсез...
Әниең... ул бездән китте...
Миннән китте... Сездән дә...
Борылып та карамады
үзен бездән өзгәндә.
Әгәр дә борылган булса
ул Лот* хатыны сыман,
күрер иде — ничек җаным
ватыла, ничек сына...
Юк, таш тоз баганасына
ул әверелмәс иде —
миңа Аллаһныкы түгел,
миңа парткаргыш тиде...
Ул хыянәт итте миңа...
Тәнгә түгел... Җаныма ...
Терәк булудан баш тартты
мин чайкалган чагында.
Кемдер каерып бөккәндә
умыртка баганамны,
ул сындырырга тырышты —
җай эзләп кабаланды.
Миңа кер кунмаган чакта
горурланды, табынды.
Ә кер кунгач, аждаһадан
ут үрләтеп кабынды.
Үчләшүдә ул юхадан
уздырмы, калыштырмы,
шунсы рас — миңа тап төшкәч,
аны җен алыштырды.
Син — улым, минә оныгым!..
Ни ерак араны мин
ничә кичтем сагынудан!
Ул килеп карадымы
улыңны синең?.. Килмәде!..
Чөнки оныгы түгел...
— Ни сөйлисең, эти?.. Әллә
тилерденме син бүген?..

...Куерды тынлык һәм катты —
боз итеп агыз шунда...
Челпәрәмә килде тынлык
абзыйның авызында:
— Аның... ана булганы юк...
Күтәрде атын гына...
Ул — тапкан әниең түгел,
ул — баккан хатын гына...

Егетнең сораулар тулы
күзләре күзләремдә...
Нәрсә әйтергә кирәктер?
Һәм нинди сүзләр белән?
Ул хәбәргә мин үзем дә
әле ышанып бетмим.
Ә намусым кушмый икән,
минем авызым бикле.
Карашымны тиз-тиз алып,
мин тәрәзгә ташладым...
Гаҗәп! Нигә селкенмиләр
икән каен башлары?
Нигә күгәрченнәр очмый?

Болытлар кая киткән?
Тормыш, тәрәзгә ябышып,
акварель булып кипкән...
Ә тынлык җепши башлады
һәм терелтте өметне.
Челтер-челтер килде тынлык
күзләрендә егетнең:
— Бу дөнья әллә ялганмы?
әни хәтле әниең
чын әниең булмаганда?
Инде тагы ни диим?..
Әти, бәлки, әле син дә
чын әти түгелсеңдер...
— Син, улым, минем турында
барлык шигеңне сүндер.
Синдә ага минем каным —
бар, тикшерт ышанмасаң.
Бүгенге техника өчен
моны ачыклау ансат.
— Ә кем ул мине табучы?
Исәнме?.. Кайда яши?
Нигә ул егерме бер ел
берничек тә эндәшми?..
— Гомер булса, ачыкланыр...
Саулыктан аермасын...
Менә сезнең канатларны
бернәрсә каермасын!..

Яшел чәйгә дип куелган
чынаякларга җәһәт
абзабыз «Рислинг» тамызды.
— Шуның өчен, җәмәгать,
яшьләр өчен! Аралары
һәрвакыт ачык булсын,
үзләрен дә, баланы да
Ходай бәхетле кылсын!..

Без өчебез эчеп куйдык...
Егет уйларга талган...
— Әнисез иткәнең өчен,
ахры, кичерә алмам, —
диеп, егет иң соңыннан
эчеп куйды авырдан.
Күрәсең, аның хисе дә,
акылы да авырта
көтелмәгән яңалыктан
алган тирән ярадан...
Нишлисең, Ходай кешене
сынар өчен яраткан.

Тапканы түгел, бakkаны,
көләргә өйрәткәне,
теле түгел, җаны белән
«Балам!» диеп әйткәне,
үз гадәтен сеңдергәне,
иңдергәне үз аңын,
күкрәк сөте бирмәсә дә,
чыны була ананың!
Табучы белән багучы

бер үк хатын булмаса,
балага юнәлгән бәхет
ялгыш сукмакка баса...

Үз канына тоташтырып,
үз тәненнән тән бүлеп,
юктан бар итүче дә бар
багу-караудан элек.
Дөньяга чыгаручы бар,
буйсынып тәкъдиренә!
Аны кайларга куясың
яшәеш тәртибендә?!
Табучы белән багучы
бер үк кеше булсачы!
Икесе ике булганда,
бала язмышы ачы...

Әни, әни, әни, дибез!
Изгедән-изге, дибез.
Әти дә бар! Изгелектә
әнигә әти тигез.
Тамчыдан елгалар туа!
Чаткыдан ут ярала.
Орлык белән үсентене
буламыни аралап?!

Асылда, һәркем өчен дә
кадерле һәм игез сез,
ӘНИ дигән түбә сүз һәм
ӘТИ дигән нигез сүз!

Пылауны сүзсез ашадык —
тостсыз-фәләнсез генә.
Табын инде кералмады
без күнеккән эзенә.
Ләкин тынлык йомшый төште,
сулуга тыгылмады.
Киленнәр чәй өләшкәндә,
абзый иркен тын алды.
Ул куелган максатына
иреште булса кирәк...
Аумый калды, ватылмады
«Улым!» дигән зур терәк.

Башкалага китте абзый...
Йөрәк тулы «Җиңәбез!»
Аны шунда көтә бугай
безнең яңа җиңгәбез...

**15**

Абзый китеп барган кичне
яшьләр килеп керделәр,
һәм безнең дә табак-савыт
шылтыравын күрделәр.
Кичәге табын «тынлыгы»
кайткан йөрәккә тулып,

һәм чыга башлаган иде
«табак шылтырау» булып.
Ярый әле, алар килде —
басылдык, тел тешләдек —
тынычлыкны ватмый калдык
һәм төзекне ишмәдек...
Керә-керешкә үк егет
төбәлде минем күзгә:
— Әйтегез, дөрес идеме
кичәге теге сүзләр?
...Килен бер карый иренә,
бер минем күзгә керә —
булырга әзер иренә,
кирәге чыкса, терәк.
Ике төрле җавапның ул
икесеннән дә курка.
Ахры, бу курку аларның
икесенә дә уртак.
«Дөрес!» дисәң — әнисеннән,
«Юк!» дисәң — әтисеннән
аера торган җаваплар...
Әй, кадалып китсен лә...
Юк, кадалмый торсын әле —
үзләре ачыкласын!
«Белмим!»нең башы авыртмый,
«Белмим!..» — акыл баласы.
Әллә хәйләнеке микән?
Куркакныкыдыр, бәлкем?..
Үзенчә бәяләсен лә
«Белмим» мәгънәсен һәркем...
— Белмим!..— дидем,— белмим, ләкин
әтиең җитди кеше!.. —
тиле түмгәккә утырмас,
акыллы үрдән төшеп.

Карадым аның күзенә —
миңа да белү кирәк:
әнисеме, әтисеме
егеткә кадерлерәк,
сайларга туры килгәндә,
ул кайсын сайлаячак...
Юк, берни дә белеп булмый —
күз нурлары алача.
Тораташтай басып тора —
моң-сагышлы чибәрлек!
— Мөгаен, дөрестер! — диеп,
егет елап җибәрде...
Килен сабыйларын җәһәт
хатыныма сузды да,
кочагына алды ирен:
— Тукта, тукта! Тузгыма!
Йомшый күрмә... Тугарылма,
бушатма тезгенеңне —
мондый хәлгә калучылар
әллә бер без генәме?!
Әнә минем күрше кызы
дөньяда сыңар ятим...
Синең, әниең булмаса,
бар исән-сау әтиең,
менә дигән туганнарың,

һәм без дә бар — гаиләң!..
Әнә улыбызга янә
бәхетле язмыш телә!..—
диеп, килен улын алды,
битләреннән үпте дә,
үзе дә шыңшып җибәрде,
күз яшен түгә-түгә.
Аларга сабый кушылды
күзләрен мөлдерәтеп.
Хатыным да, түзеп-түзеп,
күз төпләрен күгәртте...
Мин дә кыя түгел икән —
тын тыгылды бугазда...
«Җитте!» дип җикерә алдым
тик пышылдап... бераздан.

Аһ, бу йогышлы елаулар!
Берәүнеке — сәбәпле.
Башкаларны бер сәбәпсез
ияртергә сәләтле.
Елый кеше һәм бушана —
җаныннан юа керне.
Елауның йогышлылыгы —
кешенең бөек сере!
Аерым-аерым яши кеше:
аерым өй, язмыш, өс-баш,
җан-тән аерым, уй-сүз аерым,
ә тойгы менә тоташ!

«Җитте!» дип җикерә алдым
пышылдап, аннан — ныклап.
Дүртесе дә бер мизгелдә
калдылар шунда туктап.
Кайсы ванныйга ашыкты,
кайсы — комгансарайга,
хатын — кухняга... Ә минем
мөмкинлекләр тарайган —
«Җитте!» дигән боерыкка
матур дәвам табарга!..
Буфеттан шешә чыгардым.
— Әзерләгез кабарга! —
табын корабыз киң итеп,
дөньяда булмаганны.
Холодильникта нәрсә бар?
Берәр нәрсә калганмы?..
— Нинди табын? Нинди табын? —
диеп, хатын кабынды.
— Нинди табын? Шундый табын...
ни... елаклар табыны.
Көлеп җибәрде хатыным,
көлеп җибәрде килен,
иренең шыңшып көлүе
хорга кушылды килеп.
Аларга карап торды да,
чәчрәтеп көлде сабый...
Мин дә көлдем өстәлдәге
рюмканы саный-саный.
Аһ, бу йогышлы көлүләр!
Бармак күрсәтү җитә —

ауган домино шикелле
әллә кайларга китә.
Көлә кеше — арта дәрте,
күңелен ямьгә төрә...
Көлүнең йогышлылыгы —
кешенең бөек сере.
Аерым-аерым яши кеше:
аерым өй, язмыш, өс-баш,
җан-тән аерым, уй-сүз аерым,
тойгылар менә тоташ!
Җиргә лозунг эләр идем,
булсам ООН башлыгы:
«Кешелекне саклап калсын
тойгылар тоташлыгы!»

Елаклар табыны шулай
көләкләр табынына
әйләнде дә, тормыш күчте
күнеккән агымына.
Чәйләр эчтек... Килен тиз-тиз
юды бала керләрен...
Егеткә уйга батарга
мин дә ирек бирмәдем —
идәндәге паласларны
алып чыгып кактык без...
Ләкин егетнең теленнән
төшми генә теге сүз:
— Мөгаен, сүзе дөрестер
этинең — ул алдашмый,—
дип, ул тузан каккыч белән
паласның сыртын кашый...

Башка җирләрдә ничектер,
безнең илнең үз эше —
көлә-көлә борчыла да,
елап юана кеше...

Яшьләр китте үзләренә...
калдык җаныбыз көеп:
этисенме, әнисенме
егет югалтыр, диеп...

**16**

Иртәгәч, йокы аралаш
мендәр аша ишеттем —
кемдер шакый кебек иде
безнең тимер ишекне.
Ул елларда тимер ишек
модага керә иде.
...Криминал түгел, ә металл
артканга күрә инде.
Ишеккә килеп тыңладым —
ишек артында тынлык...
Һәм исемемне ишеттем,
аннары — хатынныкын,
аннары абзый исемен
әйтте иртәнге кунак...
Нишлисең, ачкычны бордым

бик авырсынып кына.
Бусагада тора иде
мөлаем гына ханым.
Торышында ук сәерлек
сизелә иде аның.
Хатыным килде... Чакырдык...
Ул узды... Басып тора...
«Ни йомыш?..» диеп, текәлдек
күз белән генә сорап...
Сумкасын сул җилкәсеннән
уң кул белән төшерде...
Аның сул җиңе буш булу
күзебезне пешерде.
Күзебезне алалмадык
кесәдәге җиңнән без...
— Танышыйк! — диде елмаеп, —
сезнең яңа җиңгәгез!
Абзагызның фатирына
төштем... Ишек йозаклы...
— Соң ул бит Мәскәүгә китте —
кичә генә озаттык...
— ЦеКадан телеграмма
булырга тиеш иде.
— Килде, килде телеграмма,
ике көн элек килде.
— Аймылыш булганбыз икән...
Ярар, шатлыкка булсын,
табылганнары югалмас,
югалганы табылсын...

Чәй әзерләдек һәм эчтек
сәгатькә карый-карый —
эшкә чабасыбыз бар бит....
— Зур рәхмәт сезгә! Ярый,
мин китим теге фатирга,
ачкычларын бирсәгез...
— Ачкычын... калдырдымы соң?.. —
диде хатын терсәге...—
элгән төштә күренми бит...

Ханым сөзеп карады —
шикләнүебезне сизде...
— Аферистмы, каракмы? —
диеп уйлыйсыздыр инде...
Карагыз паспортымны...

Күзләре дымында күрдем
күңеле авыртуын.
— Ул минем кесәдәдер...— дип,
эленгән төштән алып,
ханымга суздым ачкычны...
Тораташ булып калып,
озаттык теге ханымны...
Уф, хәерлегә булсын.
Алай-болай итә калса,
сыңар кулы да сынсын...

Эшем эш булмады... Хатын
шалтырата аптырап —
икебезнең дә күңелне

шик-шөбһә тырнап тора.
Көчкә җиткердек кичне без.
Икебез дә турыдан
абзый фатирына киттек —
җиңгәбез хозурына.
Ишеккә килдек. Ә эчтә
пианино тавышы!..
Ул, саркылып, монда чыга.
Тавыш үтә сагышлы.
Тукта, тукта! Нинди көй бу —
бәгыреңә тиярлек?!
Нинди сүзләр искә төшә
көй җаена ияреп?
Кем соң... Кемне... Кемгә сөйлим...
Фатих Кәрим сүзләре
телемә килеп кундылар
үзләреннән-үзләре:
«Кемгә сөйлим серләремне? —
йөрәгем ялкын кебек;
ялкынланган йөрәгемә
берәү бик якын кебек...»
Менә бит ул көй һәм сүзнең
гениаль кушылмасы!..
Ишек шакуны онытып,
торабыз икәү басып.
Көй һаман агыла бирә...
Ул подъездны тутырган.
Хатын терсәгемә төртте:
— Кем беләндер утыра!.. —
әллә кереп тормыйбызмы?
— Килгәч-килгәч — керәбез.
Утыра икән утырсын,
кем икәнен күрәбез.

Шакыдым. Ишек ачылды,
арынды да чылбырдан,
ул безне кертеп җибәрде
чылтыр-чылтыр чылтырап...
Ханым узарга чакырды.
Зал бүлмәсенә уздык —
әзерләнгән табын тора!
Бусы — чыннан да кызык.
— Мөгаен, куркуларыннан
килерләрдер, мин әйтәм!
Уйлаганым раска чыкты —
сез килдегез! Бик әйбәт.
Рәхим итегез табынга —
танышыйк... туганлашыйк...
Булдыра алганча кордым
сезгә диеп... бу ашны...
Җайлы икән монда — базар
бик якын, урам аша.
Кичерегез инде мине —
ит, тавык турамаган.
Хатын-кызга өлгерергә
өч куллы булу кирәк!
Ә минем... бер җиңем буш бит,
кыенрак шуңа күрә.
Ә болай... эшлим, күнектем —
мин бит бала чагымнан

шулай калдым... Эләккән идем
косилка пычагына.

Әллә кайчан булган хәлдән
җаным куйды чымырдап...
Әзер идек без ханымның
язмышына чумарга.
Утырыштык. Туралды ит,
туралды ипи, тавык...
Тавык турау — ике куллы
кешегә дә матавык...
Кичке аш вакыты иде.
Барыбыз да ачыккан —
ашап тыңлыйбыз... Ул сөйли
барысын да ачыктан.
Кияүгә чыкмыйча гына
бик яшьли бала тапкан.
Тапканда чак үлми калган,
канын шактый югалткан,
операция кичергән,
реанимацияләр...
Язмышның кәкре каены
никтер аңа сөялгән.
Кулы аркасында да ул
кыенны мул ашаган.
Карьера капкасында да
түбән булган кашага.
Башы бәрелгәләсә дә,
шешләрдән, күгәрүдән
курыкмыйча алга барган,
баскычтан күтәрелгән:
тәмамлаган институт,
өйрәнгән ике чит тел...
Ә татар хатын-кызының
үсү юллары чикле...
...Ул сөйли, без чәй эчәбез
ул өләшкән торт белән.
Җиңги сыңар кул белән дә
тортны бик оста бүлә,
пычак өстенә яткыра
өчпочмаклы өлешне,
тәлинкәгә китереп сала —
бер кыйпылчык та төшми.
— Сезне сорашмыйм, болай да
мин сезне яхшы беләм,—
абзагыз белән бәйләнеш
инде күптәннән килә —
егерме елдан да артык...
Дөрес, торды өзелеп...
Хатынын да күптән беләм...
Таныш идек без элек.
Без хәтта — чыбык очлары
минем әни ягыннан.
Очраша идек авылга
кайткалаган чагында.
Мәктәп бетереп, авылдан
мин Оренбурга килдем —
кайда тукталыйм, аларның
туганнарында инде.
Беренче ел балл җитмәде...

Ташкенттан кайтты апа...
Махсус минем өчен кайткан —
сүзем хәзер шул хакта...

Кайнагач сызгыра торган
чәйнек сузды тавышын.
Иң кызыклы җирдә бүлде
ханымның сүз агышын.
Безнең чынаяклар күптән
суынган йә бушаган...
— Мин — беркатлы авыл кызы —
һәрбер сүзгә ышана
идем әле ул вакытта,
баш-күзем әйлән-бәйлән...
Ул, бер күрәзәче сыман,
сөйләде бәйнә-бәйнә
алда күрәчәкләремне:
ялгыз яшәячәксең —
ирләр иснәргә кыймаслар
гариплэнгән чәчәкне —
сау-тазалар, чибәрләр дә
кияүгә чыга алмый,
институт ишекләре дә
җиңел генә ачылмый;
эшкә керү, фатир алу
булмас әле тиз генә,
сиңа булыша алабыз
бу дөньяда без генә.
Печать сугып, миңа шушы
фатирны беркетәләр;
теләгән уку йортыма
менә быел кертәләр;
диплом алгач, рәтләшәләр
мин теләгән эшне дә —
ышаныч зур — ул кияүдә
дәрәҗәле кешедә!
— Бер шартым... үтенечем,— ди, —
арлы-бирле йөренә, —
табып бир миңа бер бала,
ләкин минем иремнән...
Һәм ауды ул тезләремә,
башын эчемә терәп...
— Коткар мине аерылудан —
иремә бала кирәк,
ә мин бала таба алмыйм...
Синдә, миндә кан уртак...
Мин балага уза алмыйм,
шуңа җаным авырта...
Иремне шундый яратам,
югалтсам — үләм, бетәм,
мине йә юләрләр йорты,
йә буар элмәк көтә...

Йөрәгемне өтеп алды
кызгану һәм пошаман...
Мин — беркатлы авыл кызы —
күз яшенә ышанам...
Елан авызына чеби
кергәндәй киттем кереп.
Ничә еллар менә нинди

гөнаһ күтәреп йөрим...
Үзегез дә аңлагансыз:
абзагыз улы — улым,
аның оныгы — оныгым...
Хәзер гаиләм тулы.
Хәзер язмышым яктырыр
дигән ихлас уем бар...
Дөрес, беркемне бизәми
без уйнаган уеннар...
Күтәргән соңгы айларда
миңа да акыл керде —
«Баланы бирмим!» диеп, мин
үз-үземә сүз бирдем.
Бала тапканда үлгәнмен —
клиник үлем орган...
Яныма һәр сәгать саен
абзагыз килеп торган.
Атналар буе йөргән ул
һәм торган мине карап.
Ә баланы алып киткән
чын этисе буларак...
Романнарда гына шулай
ачка мач килеп тора.
«Ходай кушкан!» дигән фикер
йөрәккә оя корган...
Һәм килештем язмыш белән...
Гөнаһ дип уйлыйсызмы?..

...Тынлык егылды табынга...
Егылган тынлык сызлый,
сулыгуы безгә күчә...
Сүзсез калды телебез,
юкса сорауны җавапсыз
калдырмаска телибез...
Ни әйтик?! Нечкә уйлап та
юанга юлыгыла...
Без — хәтта пәйгамбәр түгел,
без — Аллаһ колы гына.
Нәрсә әйтик?.. Әнә әйтсен
ЦеКа комиссиясе!
Россиядә комиссия —
иң зур акыл иясе.
Абзый кайтсын. Әгәр кайтса
партбилетын күтәреп,
димәк, гөнаһ гөнаһ түгел,
димәк, гафу итәрлек...
Мин баш ваткан чакта хатын
сорап куйды сорыйсын:
— Улыгызны бер тапкыр да
күрмәдегезмени соң?
— Мин ярты еллап авырдым...
Һәм хат алдым ападан:
«...зинһар, балага күренмә,
кертмә аны хатага,
икеләнми генә үссен...»
диеп язган ялварып...
Мин аны берничә тапкыр
күрдем Ташкентка барып...
Яшеренеп һәм ерактан...
Җитте шуңа түземем...

Якынаерга кыймадым,
теләсәм дә өзелеп...
Беләсезме, тугачтан ук
аны күрә алмавым
ерагайткан булган инде
ана хисен аңлауны.
Хәзер дә килә күрәсем —
Җенем шундый котырта!
Әзерлексез эш — ахмаклык
булыр диеп бик куркам.
Мине э т и с е  х а т ы н ы
йә  ү з  э н и с е  диеп
танырга тиешме башта? —
шул чертә арка миен,
тәнемә калтырау салып,
сулуларыма — тышау...
Әтиләре кайтсын әле —
ул менә ничек кушар...

Авырдан авыр сораулар
аңыбызга абынды...
Янә тынлык урап алды
безнең кыен табынны.
Өченче көн тынлыгымы,
әллә инде яңамы?
Яхшылыкны йотканмы ул
йә йотканмы яманны?
Шул тынлыкны без сулыйбыз —
җаныбызга ни күчә?..
Авыр икән тынлыклардан
чыга белү кешечә...

Арытты сәер хәбәрдән
туган тынлыкны тыңлап...
— Әллә уйныйсызмы?— дидем,
пианинога ымлап.
— Бераз уйныйм... Аккордеон
уйнаган шикеллерәк.
Музыка мине һәрвакыт
ниндидер назга төрә.
Мин җыр көе генә уйныйм...
Ләкин бүген уйнамам —
бүген акыл гына түгел,
бүген хис тә уйлана...

**17**

Яңа җиңгинең тагын да
унбиш көнләп ялы бар.
Казаныбыз ошап китсә,
озайту хыялы бар
үткән елдагыдан калган
көннәре исәбенә.
Әлбәттә, абзый эшләре
уңайлы килсә менә
бик тә әйбәт булыр иде!
Ул ышана: барыбер
партия кальбенә каткан
ортодоксаль кар эрер,
ялгыш сүз белән ниятне

бутаудан арынырлар...
Шагыйрьне милләтче дию
акылдан ары тора...
Шагыйрь, ни генә язса да,
яза зурлап милләтен!
Шунда һәр милли әсәрнең
халыкара кыйммәте.

Җиңгәбез Казанда калсын...
Ә мин очам Мәскәүгә,
өч тиенлек документны
әйләндереп бик дәүгә,
чөнки Мәскәү бөтен илгә
баш кала, йөрәк кала,
һәр бетчә дә тишелергә
Мәскәүдән рөхсәт ала...
...Эшемне бик тиз бетердем —
Васильево «хрустале»
яулый алмаган киртәләр
калыкмаганнар әле!
Мәскәү гостиницаларын
телефон белән капшап,
тапкач үзен, абзыкаем
аптырап калды, каушап...
Чакыру көтеп ятышы
телефонга ябышып —
менә-менә югарыда
хәл ителә язмышы.
Мин дә кич китмәскә булдым —
командировка бара!..
Утырабыз абзый белән
Карл Маркска карап,
«Метрополь» бинасындагы
кафе тәрәзәсеннән...
«Канәгать микән үзенең
бөек күрәзәсеннән?»
дип сөйләшәбез, абзыйның
хәлләрен куша-куша...
Ә аның уйлары таркау,
ә аның эче поша,
әледән-әле, тыгылып,
угалый сул куенын...
Арыткан да, көч тә бирә
аңа намус уены...
— Яңа җиңгәгез — молодец! —
катышуы ярады:
тәмам аклап бетерде бит
мине — «бала карагы»н.
Үз баласын үлеп яткан
анасыннан алганын,
шуның аркасында гына
бала исән калганын
исбат иткән, ышандырган,
документлар юнәтеп...
Шуның өчен җиңгәгезгә
рәхмәт дими, ни әйтим?!
Гаепнең бусы алынды
суд-фәләннән башка да...
Үзгәрә, брат, үзгәрә
безнең бөек башкала —

якыная бит халыкка!
Сиңа күренми мәллә?
Миңа күренә — чыгам бит
җүләрчә тупик хәлдән.
Ә гаебемнең тегесе —
милләтчелектәгесе —
хәтерләтә җил аттырган
күсе-тычкан тәбесен:
тавыш булган, тәбе капкан,
үтәп кемдер теләген...
Әйдә, яз бер афоризм:
«Җил тәбегә эләкми!»
Шагыйрь дә — җил, браткаем!
Мин — шагыйрь, димәк, мин — җил.
Аһ, аяныч!.. Яманлыкка
өйрәтми Талмуд, Инҗил,
өйрәтми Пятикнижье,
Ведалар, изге Коръән...
Шул китаплардан кешегә
әхлак нурлары кергән!..
Мин дә менә үзбәкчәдән
күчерәм урысчага,
үземдә исә ургылып
чын татар каны ага...
Шуны әйткән өчен генә
эттәй каныгып, шашып,
нигә кирәк булган икән
кимерү кеше башын?!
Чит телләрдән ят телләргә
тәрҗемә, миңа калса,
җан җылысыз... Россияне
псевдошигърият баса...
— Яңа хатының Казанда...
Танышып та өлгердек! —
дигән идем, абзыкайның
йөзенә нур йөгерде.
— Кайтырга тиеш иде шул...
аймылыш булдык... Ярар,
ничек соң яңа җиңгәгез?
Вердикт нинди? Карар?
...Абзый миннән җавап көтте...
ләкин мин ашыкмадым —
нинди булса да җавабым
булыр күк ялгыш адым.
— Язмышы катлаулы икән...
Син дә амеба түгел...
Арыткан иде башваткыч
чишеп ятулары гел...
Син бит аяклы сер идең.
Җиңги ачты барысын —
син бер татар романына
геройлыкка ярыйсың.
— Юк ла!.. Ә җиңгәгез менә
чып-чын роман герое!..
Күңел генә тынычлансын —
бар әле минем уем
аның турында поэма
яки повесть язарга...
Аның турында уйласам,
хаста җаным тазара...

Тукта... Заман геройларын
татар язучылары
ник заман узгач язалар,
хөкем генә чыгарып?
Ник бәя бирә алмыйлар —
киләсе көн бәясен?
Аһ, татар язучысының
аңы артык сәяси!..
Хәтта Тукай хали түгел
хаталар очрагыннан... —
алтын каләмен манчыган
сәясәт пычрагына...
Күзе бүгенгедә генә
татар язучысының...
Ә бит киләчәккә ага
тарихның ташкын суы...
Татар романчысы өчен
тарих ул — бармак-җилен:
имә — яза, имә — яза,
ә бәһаләүче тиле —
әкиятне чын тарих дип,
бик теләп кабул итә.
Әкият ялтырап торса,
татарга шул бик җиткән...
Уйдырма авторларына
ява зур-зур исемнәр —
шул исем бирүчеләрне
«Татар җанлы!..» дисеннәр,
чөнки инде шушы шаукым
күпләр аңына тамган...
Татар җанлы булу — артык
чын кеше булудан да!..

— Ихлас әйтәм: ул персонаж
булырга лаек ханым —
күңеле бай, рухы көчле,
ихтыяры нык аның.
Бер ким урынына аңа
биргәндер Ходай мең им!
Им балкысын өчен кимне
күреп күрмәү бик мөһим.
Шунда җиңгәгез ачыла
Сим-сим капкасы сыман
һәм кайта гаҗәеп җылы
балкышлы асылына...
Хатыным таныштырганда,
җаным китте имәнеп —
һич тә күргәнем юк иде
андый матур имгәкне!
Бер француз рәссамының
«Шоколадница»* дигән
әсәре бар бит! Әйтерсең
шул сурәткә җан иңгән!
Күзләре генә авылча —
куркак һәм аптыравык —
хистән мөлдерәп торалар,
китәрләр кебек агып.
Карашында — кимсенүдән

тамырланган сизгерлек;
яшәгән бит горур җанын
гариплектән іздереп.
...Хатын куйган максат белән
мин Оренбурга килдем...
Ял йортына алып киттем
чыгын коймаган гөлне...
Күнегә алмый йөдәде,
куркудан аптырады...
Һәм, апасын әрли-әрли,
ясады кыю адым...
Бөтен эшләр булды безнең
бер тапкыр да үпмичә —
мин китәргә тиеш идем
аны гашыйк итмичә.

Бер атнадан китеп бардым
фатирында калдырып...
Һәм Ташкентта Оренбурдан
хәбәр көттек каңгырып...
Ике айдан хәбәр килде —
көткәне, теләгәне!
Хатыным елап җибәрде,
бәгыре телгәләнеп:
«Йа Ходаем, кичерә күр,
нинди зур гөнаһ алдым —
үз иремне үзем теләп
чит кочакларга салдым...»
Һәм арага нидер керде
булса кирәк шул кичтә.
Син теләгәнгә генә, дип,
тынычландырдым көчкә...
Һәм бераздан, эшен ташлап,
тиешле кием киеп,
ул Җаекка китеп барды,
балага уздым, диеп.
Мин, борынгы чәчүчедәй,
хәбәрне учлап-учлап
сиптем Ташкент урамына,
шатлыктан оча-оча...

...О! Баланы алып кайту!
Һәм юу тәпиләрен —
хикәя итеп язарлык,
әкият итеп сөйләрлек!
Кыскасы, малай үстердек,
аңа пар канат булып.
Ләкин нигәдер миңарак
тартыла иде улым.
Хатынымның көнләшүе
күзенә чыга иде —
салкын нур, чыбыркы булып,
йөрәккә суга иде...

Йә, җитте аның турында —
ерак калды, өзелде...
Ну, яңа җиңгәгез ничек?
Әйт инде бер сүзеңне.
— Сиңа ничек — безгә шулай! —
дидем күзенә карап.

Комплимент көткән күзләрдә
томан куера бара.
Җан — киерелгән кыл сыман,
мөһим аңа көткәне —
йөрәккә валидол кебек...
Өзелә дә китә ул...
Ык та мык килеп утырсам,
Карл Маркска карап,
сизәм, матур кичәбезне,
абзыйны итәм харап.
— Ошады! — дидем,— ошады!
күңеле җылы, якты...
Сүзләрем абзый күзеннән
юеш нур булып акты...
— Мин аңа Афродита, дим,
Чулпан Милосская!..
Ул иреннәрен турсайта,
юри генә кылтая.
— Буйга-сынга ул чыннан да
Милосская ише.
— Һәм юк аның кеше күзен
рәнҗетә торган төше.
Бер кулының булмавы да
сизелми һәм күренми —
әйтерсең ун бармак белән
капшый бөтен җиремне...
Бүген минем күңелемне
ни телә, беләсеңме? —
улым э н и дип танырмы
үзенең чын әнисен...
— Таныр! — дидем,— җанын инде
давыл тузгытып җыйды,
синең коточкыч хәбәрең
аң-зиһененә сыйды,
йөрәгенә дә сыячак!
Менә күреп торырсың,
киләчәк сиңа, киләчәк
шатлыкларның олысы.

Сөйләшәбез... Икебез дә
Карл Маркс күк аек...
Һәйкәлгә соры фон булып
тора иде сузаеп
«Москва» гостиницасы —
бик истәлекле бина.
Йә бер тәрәз, йә башкасы
йә сүнә, йә кабына.
Кемдер керә, кемдер чыга,
кайтып китә, урнаша.
Илнең барлык юлы, эше,
акчасы — Мәскәү аша.
Мәскәү — рөхсәт, Мәскәү — капка,
ул —ышык, янау, сынау...
Мәскәү һәркемгә дә кирәк,
Мәскәүсез булмый сулап,
урамыңа исем кушып,
бакчаңда мунча салып...
Башкаланы менә ничек
күтәрә безнең халык!

— Гостиницага карагач,
кода исемә төште —
ни әйтсәң дә, ул гаҗәеп
булган һәм уңган кеше.
Җитәкчеләр карар кыла,
мондыйлар бөтерелә,
аларның аяк эзеннән
дәүләткә байлык килә.
Син моны яхшы аңлыйсың,
син — мәгълүматлы кеше:
нефть-фәлән алып булмый
бармак белән җир тишеп.
Карар — кәгазь, эш — бары көч,
алар тоташсын өчен
механизмнардан битәр
кирәк тәэминат көче!..
Кабатлыйсы иде теге
танышу кичәбезне...

...Официантка килде дә
абзыйның сүзен өзде.
— Теләсәгез, берәр рюмка... —
дип әйтте кашы белән.
— Юк!— диде абзый,— рюмкадан
борчылу ташый гына...
Миңа әйтте:
— Җиңгәгезне,
йомышы булса, борма...
Мин кайтканчы, улым белән
ничек тә очраштырма...

Иртәнге самолет мине
Казанга алып китте.
Абзый калды башкалада
ЦеКадан хәбәр көтеп.

Болытка керде самолет...
Ни җир, ни күк күренми...
Ходай күк гөмбәзен сөрткән
мамыкларга төренеп,
каядыр оча самолет,
куркуыннан дерелди...
...Һәм иллюминаторларда
зәңгәр гөмбәз күренде...

**18**

Абзый Мәскәүдә чагында
булмады күк берни дә...
Бары җиңгәбез һәм яшьләр
безгә килеп йөрделәр
Мәскәү хәбәрен белергә.
Очрашмадылар ничек!
Бәлки, очрашканнардыр да
баскычта, үткән кичне —
яшьләр чыгып кына китте
абзый хәбәрен сорап,
кыңгыравын чылтыратып,
ишектә җиңги тора.

Әй бу телефон юклыклар!
Россия киңлегендә
җәяүләп, суда, һавада
йөретми кемне генә!
Телефоннан бер секундта
аласы мәгълүматны
тәмам картаеп бетәбез
хат аша көтеп ятып.
Илебез зур, ә юллар юк —
Генсек үртәлсен иде,
һәрбер өйгә телефонны
көчләп кертәсе иде.

Җиңгинең дулкынлануы
чыккан йөзенә бәреп:
— Котлагыз, котлагыз мине —
килде матур хәбәре!
Телеграмны миңа сузды.
Йа Хода! Җиңгән! Җиңгән!..
Арка белән шуып төшеп,
идәндә үкси җиңгәң...

Тагын ике көн көттереп,
абзый да кайтып төште.
Аның кыяфәте башка,
ул инде башка кеше —
Мәскәүгә кергән Бонопарт,
Болгарны алган Батый!..
Петр-Бер кебек утыра
һәм Жуков кебек атлый!

Якшәмбе иде... Поездан
безгә кайтты туп-туры.
Күзләре билгесез, сәер
нурлар белән тутырук —
борчылу катыш шатлану!
Була шундый хәлләр дә —
аптырыйсың: котларгамы?
Әллә инде җәлләргә?
— Кайтардылар!..— диде абзый,
партбилетын чыгарып, —
кызганыч, бездә сәясәт
мең хаклыктан югары...
Кайвакытларда хаклык та
югары калкып ала —
сәясәтнең тешләреннән
йөрәген тартып ала.
Кечкенә генә хаклыкның
мин дә йөрәге идем,
миңа да кансыз явызның
үткер тешләре тиде.
«Менә ул оеган каным!»
дип кызыл партбилетын,
өстәлгә чамалап торып,
урындыкка ыргытты.
Өстенә барып утырды.
— Ул миннән өстен иде,
ә хәзер менә астымда.
Чәй бирәсезме?— диде.

Иртәнге чәй көн-тәүлекнең
бисмилласы, догасы!
Иртәнге чәй тәме белән
якты көнгә чыгасың,
кичкә кадәр кайнарлыгын
саклыйсың дәрманыңда.
Иртәнге чәй тәмле булса,
валлаһи, эшең уңа.
Безнең чәйнең ни өчендер
булмады тәме-рәте —
утырдык авыз эчендә
буш сүзләр тәгәрәтеп.
Абзыйда шатлык күкләргә
ашарга тиеш иде,
ә куаныч канатлары
нигәдер юеш иде.
Һәм минем дә тел очыма
еш килде бер үк сорау...
Ахыр чиктә әйтеп салдым,
тормадым урап-урап:
— Ник әле турыдан-туры
син өеңә кайтмадың?
Ник хатыныңа бирмәдең
куанычың каймагын —
юкса аның тырышлыгы
китерде бу уңышка...
— Җитте инде... Шик өстенә
шөбһә өстәп булышма...
Партбилет, беләсең килсә,
бары тик амбициям
проблемасы гына иде...
Бүген башкадан көям:
хатыным белән улымны —
һич башым эшләп җитми —
ничекләр таныштырырга
а н а белән у л итеп?..
Шуңа сезгә кайтып төштем,
Киңәш өмет итәмен,
үзем генә уйлый-уйлый,
җиттем инде чиккә мин.

Тагын тынлык чәй өстәлен
каплап алды япмадай.
Астында без. Уйларыбыз
акмады бер якка да.
Мондый чакларда хатын-кыз
акыллырак ир-аттан...
— Моны эшләргә кирәктер
аерым-аерым... чиратлап.
Иң алдан — хатының итеп...
Кабул ителә калса,
«Ул — чын әниең бит!»— дип
әйтүе булыр ансат...
— Белмим, белмим,— диде абзый
кистереп, тере генә, —
улым аны ошатмаса
беренче күрүеннән?
Ни дисәң дә ул бит аңа
теге әни көндәше!..
Күрдегез ич теге көнне

ир-егетнең күз яшен!
Ошатмаска тагын сәбәп —
җиңгәгезнең буш җиңе...
— Анысы өчен борчылма,
ул — кызгандыру җиме.
Кызгану җанның бозларын
эретә дә агыза, —
диеп, лекция укыды
хатыным абзабызга.—
Бик тә беләсегез килсә, —
кем теләсә ни дисен —
кызгану катыш соклану
тудыра сөю хисен,
ә хатыныңның, беләбез,
сөйкемле сөяге бар...
— Улыңның билгесезлектән
котылу теләге бар,
димәк, эшләр җайланырга
өметебез нигезле...
— Ярар, сезнең җылы сүзләр
мине күккә тигезде, —
диеп, абзый чыгып китте,
үзен-үзе онытып...
Урындыкта калган иде
җып-җылы партбилеты...
Шунда ук ишек шакыды...
Гадәтләрне бозмыйча,
партбилетын сорап алды
бусагадан узмыйча.
— Бүген эш уңмастыр!..— диде, —
кердем кире борылып,
минем кайтканны яшьләргә
әле әйтми торыгыз...

**19**

Дүшәмбе — авыр көн, диләр...
Әйтәләр һич белмичә —
дүшәмбе ул — уңайлы көн!
Сынадым моны ничә...
Дүшәмбе ул — атна башы.
Әйе, башлау катлаулы.
Ләкин уңышлы башласаң,
нинди рәхәт атлавы
сишәмбе, чәршәмбе буйлап
пәнҗешәмбе, җомгага,
ә алда бит шимбә белән
якшәмбе көн ым кага,
вәгъдә итеп шашлык, уха
һәм талонлы аракы.
Ә талонлы аракы ул
чикләгәнне яратмый.
Иртәгәсен чатный башлар,
үтереп сызлый бавыр...
Шундый чакларда, чыннан да,
дүшәмбе көннәр авыр.

Ә безнең дүшәмбе көне
әйтемнәргә төкерде...
Эшкә барып кына җиттем,

кодабыз килеп керде —
ниндидер медаль алырга
Казанга чакырылган...
— Кич — ресторанга!..— диде ул, —
бер юыйк матур гына.
Хатын да килде. Ул хәзер,
бар дөньясын онытып,
куанычтан чиный-чиный,
иркәлидер оныкны.
Кода кайттымы Мәскәүдән?
Ул шалтыраткан иде —
эшләр җайланырга тора
бүген-иртәгә, диеп.
— Кайтты,— дидем,— кичә кайтты...
— Шатлыгыннан ташыпмы?..
Вакыт бар әле,— дип, кода
абзыйларга ашыкты...

Кич җыелдык Чәй йортына —
аракысыз табынга...
Һәркайсыбыз яшереп кенә
«теге» чакны сагына.
Бигрәк тә — кода дуслары...
Алар әнә тазалар,
ләкин абайлар — гәзитләр
бит тутырып язалар
илкүләм эчкечелеккә
уңышлы һөҗүмнәрне,
фаш итәләр, оялталар
бик мәшһүр исемнәрне...
Самогон аппаратларын
үзләре теләп ваткан
кешеләрне олылыйлар,
күккә чөяләр мактап.

Барысы да килеп бетте...
Яшь гаилә — туп-тулы.
— Әти кайтмадымы әллә? —
диде абзыйның улы.
...Мине уздырып, җавапны
кода биреп өлгерде...
Нәкъ шул вакытта ишектә
яңа җиңги күренде...
Әлбәттә, абзабыз белән!..
Газ шәльяулык иңендә —
Мәскәү театрларының
примасы кимендә!..
Казан урамнары тулы
һуш алырлык хатын-кыз,
ә театрларыбызда...
Хәтта әйтү уңайсыз...
Кагыйдәдән искәрмәгә
чыксак тырышып атлап,
бар, әйтик, Мотыйгуллина,
Гайнуллина ТДАТта,
операда — утыз еллап
унсигез яшьтә шилә*
(шулай булып калачак та!)
Сөнгатуллина Зилә...
Аһ, талант ияләренә

кыяфәт җәлли Ходай.
Матурлык алдында бүген
татар гөнаһлы бугай...
Ә иртәгә? Ә «иртәгә»
татарга озак килә...
Татар матурны үстерми,
үскәнне ашый белә...

— Җәмәгатем! — диеп, абзый
хатынын тәкъдим итте,
аны, җил булып этәреп,
улы янына илтте
һәм кочаклап алды улын,
киленен һәм оныгын...
Һәм аларны кочкан килеш
җибәрде ул сулыгып...
Табыннан гафу үтенде:
— Шатлык бит, шатлык!— диде.
...Бу сүзләрне һәркайсыбыз
үзенчә аңлый иде...

Коданың бүләген юдык —
орден булып чыкты ул.
Мактадык нефтьчеләрне,
теләдек уңышлы юл.
Кода нефть якларында
билгеле кеше икән,
күп уңышлар нигезендә
аның өлеше икән!
Бу орден аңа күптәннән
булырга тиеш булган...
Аның каравы — орденны
алды беренче кулдан!..
Юдык, әлбәттә, чәй белән!
Чәй йорты хуҗалары,
дөрес, зәхмәтле суны да
тәкъдим итеп карады.
Без баш тарттык горур гына,
янәсе, эчүсез дә
күңел ачарлык культура
сакланып калган бездә!

Нефтьчеләр җор булса да,
сүлпән иде табыны,
очкын хисләр ава иде,
сак акылга абынып.

Абзыйның улы, килене
ханымнан күз алмады.
Аларның күз карашлары
еш кисеште-ялганды.
Шундый чакларда егетнең
кабынып алды җаны —
йөрәге дә, акылы да
тибәрми иде а н ы.
Шуны сизеп, ул эченнән
куанып куйды хәтта...
Хатынының колагына
пышылдады шул хакта.
Әтисенә карата да

нәфрәт хисе сизмәде...
Тигез иде, тигез иде
аның күңел бизмәне.
Ә менә килен җанына,
әйтсәк турысын-чынын,
рәхәт җил булып кагылды
ханымнан килгән җылы.
Аларның күз карашлары
очрашкан мизгелләрдә
күңелләре тәрәзендә
ачыла иде пәрдә,
эчкәрәк дәшеп-чакырып...
Тартынып елмаешып,
күз карашларын башкага
юнәлттеләр ашыгып:
ханым — тостчыга, ә килен —
итәктәге улына...
Ул беренче булып дикъкать
итте ханым кулына.
Бераз ышанмыйча торды...
Ышангач, урап-урап,
иренә дә пышылдады,
сүзеннән курка-курка.
Ә тегесен биләп алды
куркулы кызыксыну.
Күзләре а ң а беректе,
хисләренә буйсынып.
Ничек соң ул күрми калды?
Ни томалады күзен?
Күпме генә баш ватса да,
әйтә алмады өзеп.
Ул кызганып куйды а н ы...
Ләкин җаны бизмәде...
кузгалды, ләкин кузгалды
аның күңел бизмәне,
этисе янына барып,
иңенә генә тиеп,
бик әйтәсе килде аңа
«уңайсызланма!..» диеп.
Егетнең уйларын бүлеп,
кузгалды шунда кода:
— Минем орденнан да өстен
шатлык бар әле монда —
кичә кода партиядә
яңадан торгызылды!
Шуңа рөхсәт йөз граммны
кире какмаска булдым —
китерегез, туташкайлар,
безгә «фронтовой»ны,
кодам куанычы миндә
сабантуй булып кайный...

Китерделәр... Тотып куйдык,
Ир-атлар гына эчте,
хатын-кызлар порциясе
безгә — ирләргә күчте.
Абзый торып басты тостка...
— Рәхмәт... Ни дип куаныйм?..
Йөрәгемне тотып әйтим —
өр-яңадан туам мин.

Партбилет даулап йөргәндә,
гаҗәеп билет таптым...

...Абзыйның паузасында,
күзгә ияреп, чаптым
табын буйлап... Нефтьчеләр
җитдиләнеп тынганнар.
Җиңги, башын аска иеп,
җилкә белән тын ала.
Кодагый терсәге белән
кодага куйды төртеп.
Минем хатын да нәкъ шулай
уяулыгын белгертте.
Яшьләр улларын көйлиләр,
имезлек төртә-төртә...
Һәр кеше шулай абзыйдан
үтә мөһим сүз көтә.
Абзый сүзен дәвам итте,
яшьләр янына атлап:
— Бу — үлемсезлеккә билет!
Фамилиямне саклап,
киләсе гасырга чыгар
оныгым туды менә!
Әйдәгез, соңгы йотымны —
онык исәнлегенә!

«Уф!» диеп куйды хатыным.
Җиңгәбезгә төс инде.
Без дуамал абзабыздан
башканы көткән идек...
Баш өстенә, туры кулга
күтәрде ул оныгын:
— Мондый билет бар чагында
башкаларын онытыйк! —
диеп урынына кайтты,
тулы рюмкасын тотты
һәм сабыйны җиңгәбезнең
итәгенә утыртты...
Аңышырга өлгергәнче,
сабыйга әллә каян
тартып чыгарды җиңгәбез
кызыл колаклы куян.
Шыңшырга җыенган бала
уенчыкка алынды...
Килен һәм җиңги күзләре
тагын ялганып алды...
Инде алар бер-беренә
баш белән ым кактылар,
һәм сизделәр: сүзсез-нисез
уртак сүзләр таптылар...

Бу җиңгәбезнең җиңүгә
тәүге адымы иде!
Бу — абзыйның һич көтмәгән
солых табыны иде!
Бу — Әлмәт кодаларны да
сискәндергән чак иде —
аларны кайбер серләргә
бераз керткән чак иде.
Бу — егетнең керпелеген

йомшарткан кичә иде,
ул хатыны салып биргән
җылы сүз эчә иде,
ләкин һич аңламый иде
эчкәне хасиятен,
алып керә иде хатын
үзе белән ияртеп,
савылмаган җилен кебек,
наз куерган күңелгә...
Ирен анда ни көткәнен,
ни күрәсен кем белгән...
Абзабыз белән җиңгәбез
уйланганнардыр озак —
сиздермичә керде ачкыч...
Ачылды микән йозак
әтисен һичберкемгә дә
җибәрми торган юлда?
Кабул ителмәдеме бу
булып тик алдау-йолдау?
Җиңгинең миен, мөгаен,
шушы шик-шөбһә яра...
Әтиеңне ят хатынга
биреп җибәреп кара!..

Килен, килеп, җиңгәбездән
алып китте сабыен...
Абзый йөзе елмаюлы,
ә күзләре сак иде...

Мәҗлес матур чакта бетте —
дәррәү бергә куптык та,
Чәй йортыннан чыгып киттек,
хатыннарны култыклап.
Абзыйлар — ике гаилә —
тартышмыйча, бик теләп,
берсен-берсе кыстый-кыстый,
бер таксида киттеләр.

Алар киткәч, хатын әйтте:
— Алдан күрдем аны мин —
әтисенә хатын итеп
таныды ул ханымны...
...Кодалар кунакханәгә
кайта җәяүләп кенә.
Озата барып сөйләштек.
Алар да әйбәт кенә
кабул иткәннәр ханымны:
— Беренче күрүемнән
бик таныш һәм бик үз булып
керде ул күңелемә, —
диде кодагый,— ә ч ы н ы н
күреп булмады бер дә...
— Ходай кушып, анысын да
насыйп булсын күрергә...—
дип әйтеп, мин бу теманың
тамырын чабып өздем...
Һәм «бишенче» «утырамвай»*
утыртып китте безне,
«икенче» кирәк булса да...
Ә без тизрәк теләдек —

абзыйдан узып, бу хакта
сөйләшәсе килмәде...

**20**

Беркайчан да булмаганча
кабалана-ашкына,
яңа партбилетын тотып,
үзенең Ташкентына
очты да китте абзабыз,
селен барабан алып...
Оренбурга билет көтеп,
җиңгәбез тоткарланды...
Аңардан белдек: Казанга
күчәчәкләр! Һәм тиздән...
Әйе, әйе, җәй аенда,
һич калдырмыйча көзгә.
Җиңгәбез сөенгән — аны
яшьләр кире какмаган!
Әлегә шунсы да җиткән
йөрәгара капкага.
Һәм ышана капкага ул!
Әле без дә котларбыз —
улым, дигән,
ә н и, дигән
сүзләр йөрер тоткарсыз
йөрәгара капка аша —
түземлек кенә бирсен!
Уйлары гына улының
кергән юлыннан йөрсен...
Аллага шөкер — сынауның
четереклесе үтте...

...Иртәгәсен җиңгәбез дә
Оренбурына китте...

Җәйнең балалар рәсеме
кебек беркатлы чагы —
җирдә чирәмнең яшеле,
күктә болытның агы.
Суларда дулкыннар зәңгәр,
ярларда комнар сары.
Ак болытлар арасыннан
алтынсу кояш карый...
Куак күләгәләрендә
песи, эт тора ятып...
Һәм без гомер кичерәбез
мең мәшәкатькә батып,
буйсынып үзебез сүккән
законнар, указларга,
үзебез үк рөхсәт биреп
шундыйларны язарга...
Гомердән гомергә үскән
йөзем бакчаларында
балта уйный... Шатланабыз:
ил агудан арына!
Һәм боларны эшлибез без
Ватанны бизәр өчен —
аеклык җәмгыятьләре
һәр җирдә төзер өчен,

беравыктан ул кормалар
бетсен өчен ябылып,
алар бетү шатлыгыннан
эчәр өчен егылып...

Ә Казан урамнарында
тополь яфрагы исе
шундый куе, була хәтта
май кискән кебек кисеп!..
Хуш ис тагы да куера
үткәч ике-өч атна
һәм, әйләнеп ак мамыкка,
Казанны ала каплап.
Ярты халык сүгә башлый
«хатын-кыз» топольләрне...
«Тополь — һава чистарткыч!» дип,
бусы тегесен әрли...
Мамык тула һәр тишеккә,
һәр кытыршыга сыра,
әйтерсең лә иң бәйләнчек,
иң котылгысыз сорау!..
Бу котылгысыз мамыктан
җанлы һәм җансыз — гарык!
Яңгыр кирәк! Көчле яңгыр
коткара ала бары!

Шундый кичләрнең берендә,
батып тополь карына,
абзый улы килеп керде —
йөзләре агарынган.
— Мине,— ди,— бер сорау борчый,
ычкындырмый ялгыш та —
тополь ботагыдай авыр,
мамыгыдай ябышкак.
Рәтләп имтиханнарга да
әзерләнергә бирми —
кичә шуның аркасында
бирә алмадым берне.
Бу соравым җавабының
аңлыйм, аңлыйм хакын мин...
Әтинең яңа хатыны
мине тапкан хатынмы?
Җавабыңны бир дә, китәм...

Эчемә суык тулды,
тополь мамыгы күренде
гыйнвар зыкысы булып...
— Синең акыллы башыңа
ничек килде бу сорау? —
дип, нокдауннан айнырга
тайм-аутта торам.
— Чәй йортында төшерелгән
фотолар карагандa...
— Әллә алар өлгердеме?
Ни-нәрсәләр бар анда?
Йәле, алып та килдеңме?
Уз әйдә, без дә күрик —
аек өстәл тирәсендә
кабат хисләнеп йөрик...
— Менә, менә үзең кара —

бу күзләр, борын, битләр!..
Күргән бөтен кеше әйтә:
без охшаганбыз бик тә...
Аннары...үзем дә күрәм...
Йөрәгем дә сизенә,
ләкин нәрсә сизенгәнне
аңлап булмый тиз генә —
хисләр фикер булып җитми,
сүз табалмый өзелә...
Шуңа күрә әйтә алмыйм
ул тойгыны сүз белән...

Ярдәмгә килде хатыным —
чакырды чәй эчәргә...
Йа хатын-кыз сизгерлеге!
Ул бит башка күчәрдә
әйләнә көтмәгән якка
иң көчле локатордай —
ир сагында гына түгел,
дөнья сагында тора!

...Чәй эчәбез... Берөзлексез
хатын сорау яудыра —
әңгәмәне йә балага,
йә имтиханга бора,
йә сөйләп китә эшендә
булган төрле хәлләрне,
кыстыра газеталардан
укып белгән хәбәрне,
зарлана баш авыртудан,
шикләнә анальгиннан —
шулай һушыма килергә
вакыт, җай бирә миңа.
Абзыйның улы һаман да
«кашый кычыткан җирен»:
кем булып эшли, булганмы
этигә хәтле ире?
Ничек кулсыз калган икән?
Тагын бармы баласы?
Институт бетергәнме?
Ничә яшьләр чамасы?
...Кызыксына төрле яклап...
Сорауларда сизелми
көнләшүләрдән ярала
торган үч-нәфрәт эзе...
Кызыксына җылы итеп...
Торган чакта җай чыгып,
чишә башламаска микән
аңа серләр янчыгын?
Әлбәттә, тәртипләп кенә,
бик төгәл уйлап кына —
юкса чәнчелеп төшәрсең
уенның уймагына.
Җиңги турында сөйләдек,
ләкин ачмадык серне —
тел ул кешегә бирелгән
яшерергә фикерен...
Тыңлады ул кызыксынып,
онытылып, ис китеп...
Һәрбер сүзне йота торды

ул тәмле тәгам итеп.
— Пианинода уйнавын
тыңласаң!..— диеп, хатын
арттыра төште җиңгинең
күкләргә ашкан хакын.
— Нәрсә, сыңар кул беләнме?
— Әйе, әйе — бер куллап...
— Паганини ничек кенә
уйнаган бит бер кылда...
— Чагыштырдың!..— диде егет,
ирене читен чытып,
һәм ирония чаткысы
күзенә бәреп чыкты.
Каш ясыйбыз дип, чак кына
күз чыгарып куймадык...
... Татар шулай — бик еш кына
артык майлый коймагын,
татар бик еш оныта шул
күп эшләрдә чаманы —
үз-үзенә, үзе белми,
шулай аяк чалгалый...
Егыла да, гаеплене
читтән эзли башлый ул.
Безнең татар бик гадел шул,
гөнаһсыз шул, башлы шул!..
Булмаган юрганга карап,
аяк сузмаска димим.
Сузылган аяк суыкта
тырпайганны да сөймим.
Уйланмасаң — яшәү рәхәт!
Уйлансаң — башың катар —
а в ы з эчендә яшибез!
Шуны онытма, татар!
«Нинди авыз?» дип сорасаң...
Җавапны бергә эзлик...
Бәлки, үз авызыбыз ук
капкандыр әле безне...

Теге бик авыр сораудан
котылдык, дип торганда,
сорау кабат яңгырады
башка түмәр органдай:
— Мине шул хатын тапканмы?
Ник әйтмисез өздереп?
...Сорау, йа Аллаһ, эчендә
җылы барын сиздерде.
Ул «Әйе!» дигән җавап та
алырга риза кебек.
Ләкин «Әйе» дә, «Белмим» дә
бар эшне бозар кебек.
— Әллә ниткән сорау биреп,
тоз саласың каныма...
Каршы булыр идең мәллә
туарга шул ханымнан?! —
дигән сүзләр, көтмәгәндә,
тешне ерып чыктылар,
икебезне ике якка
сугып торып ектылар...
Мин куркудан айнып киттем...
Ул да аңына килде:

— Кеше сайлап туа алса,
бәхетле булыр иде!..
— Юк, бәхетсез булыр иде —
мәңге сайланыр иде,
яхшырагын эзли-эзли,
тумыйча калыр иде.
Кеше бит ул сайланучан —
сөйкемсезгә сөйкәнми...
Кодрәтеңнән килсә әгәр,
туар идең син кемнән?
...Егетем уйлана куйды,
ияген учка кадап.
Студент, үзе дә сизми,
уенга керде кабат.
Уенга ныграк бәйләргә
сораулар итте ярдәм:
— Жанна д,Арк?.. Әби патша?..
Бәлки... Сөембикәдән?..
— Ә, Сөембикә, дигәннән...
институтка килде
бер яшь галим... Без аңардан
әллә нәрсәләр белдек:
әйтик, Казанны Мәскәүгә
биргән шул Сөембикә.
Сөембикә ул гомумән
татар булмаган икән.
Казаннан утыз чакрым
ераклыкта нибары
руслар крепость корганнар.
Билгеле ич уйлары...
Биш йөзләп кенә урыс бит
төзегән шунда торып...
Туздыр да кайт, туздыр да кайт
крепостьны, яндырып...
Шаһгалигә хатын булган...
Һәм ире белән бергә,
Грозныйларга кушылып,
Казанга ул да кергән...
Әгәр булсам да мин шундый
кодрәткә ия адәм,
туарга теләмәс идем
андый Сөембикәдән.
— Һай, башыңны бутаганнар!
Сөйләгәнең — җүләрлек.
Аны Мәскәүгә сатканнар...
үзебезнекеләр үк...
— Ханбикә була торып та
үзен шулай саттырган
хатыннан мин тумас идем...
— Ил өчен булган корбан,
ил өчен!..— диеп, үзем дә
чәйнектәй кайный яздым.
...Мондый фикерләр Казанда
әлегә, шөкер, аздыр...
Шулай, заман бәһаләрен
капшап карап, үзенчә
бәяләүчеләр кулына
дилбегә инде күчә.
Кая таба китәр икән
татар төялгән олау?

Урап-урап йөрмәбезме,
һәм җитмәбезме соңлап
башка халыклар ирешкән
матур, җайлы тормышка?..
Тапшырдык!.. Һәркем үзенчә
юл ярырга тырыша...

— Биралмаган имтиханны
нишләтмәкче буласың? —
диеп үзгәртмәкче идем
уйларының кыйбласын.
— Иртәгә үк биреп ташлыйм —
ул фәнне беләм яттан.
Сессия беткәч — сагындым —
Ташкентны урап кайтам —
чынлап та, әнидән никтер
булмады бер хәбәр дә.
Әти аркасында безне
ята микән каһәрләп?..
Сөйләшәсе сүзләр дә бар,
бирәсе сорауларым...
Ул өенә кайтып китте,
сорауларыннан арып...

Без һава алырга чыктык.
Ә җәйге төн тымызык.
Кемдер шәмәхә гөмбәзгә
сызык Ай куйган сызып.
Туып килүче Аймы бу?
Үлеп баручы Аймы?
Моны хатыннан сорадым...
— Шул гына булса кайгың,
әгәр чынлап та белмәсәң,
өйрәтим инде, ярар:
аны билдән түбән булган
төш итеп сыйпап кара —
уң кулыңа җайлы булса,
ул Ай, димәк, нарасый,
сулга җайлы булса, Айны
йота төннең карасы...
Мин сузылдым сызык Айга...
Сул кул белән сузылдым...
«Фәнни» ачыш кызык иде...
Никтер кәеф бозылды...

**21**

Хатыны белән баласын
озатты да Әлмәткә,
егетебез очып китте
Ташкентына, әлбәттә.
Безне йөдәткән сораулар,
мүкләк сыердай сөзеп,
нишләтеп бетерде икән
андагы җиңгәбезне?
Нәрсәгә әйләнде икән
ана — бала арасы?
Улы, тырнап, әнисенең
ачкач йөрәк ярасын,
авып киткәндер бахырың,

авыртудан аһ итеп...
Булырга гына язмасын
аңлашулар шаһиты...
Бигрәк тә — баласы белән
анасы аңлашканда...
Иң изге, якты хисләр дә
манчыла кара канга...
Абзый ни эшли торгандыр
ике ут арасында?
Кәлҗемә кебек мәлҗерәп
төшмәсме чарасыздан?..
Юк, алай булмаска тиеш,
чөнки ул ничә еллар
стресста иза чикте,
шул партбилетын юллап.
Чынықты ул ялкыннарда,
чынықты салкында да...
Инде яшәргә өйрәнде
ялкынны бозга ялгап.

Ә кайда ялгана икән
кешедә боз һәм ялкын?
Алар якынлашкан мизгел
гөлт итеп куя балкып.
Мөгаен, шундый балкышлар
фәнни ачышка, җырга,
шигырь, рәсемгә әйләнеп,
чәчри гасырга, чорга...
Ялгану йөрәктә генә,
акылда гына түгел...
Аң һәм Хисне берләштергән
урын бар ул... Ул — к ү ң е л !
Чәч очыңнан аякларың
бармакларына чаклы
били кыска ялганыштан*
җаныңда туган чаткы.
Чаткыны сүнми яшәткән,
елый һәм җырлый белгән
Киңлек, Биеклек, Тирәнлек —
к ү ң е л д е р  диеп беләм.
Күңел ул кешедән зуррак,
зуррак Җир шарыннан да:
анда — йолдызлар, чиксезлек;
киләчәк, үткән — анда;
яхшылык белән яманлык,
караңгылык, яктылык
бәрелешмичә яшиләр
субстанция булып.
Анда һәр нәрсә даими,
һәр нәрсә үзгәрештә —
нәрсәдер идарә итә
аң җитмәгән гарештән*.
Анда дөньялар ярала,
яши һәм китә үлеп...
Күңел — Аллаһы ук түгел,
Аллаһ — кеше күңеле!..

Уза матур җәй айлары —
әллә ялга чыгасы?! —
диеп ниятләр корганда —

йөрәк кенә чыдасын —
«Әти үлде Оренбурга
Әлмәткә җиткерегез
цинк табут каршыларга
хәстәрлекләр күрегез»
диелгән телеграмма
килмәсенме Ташкенттан...
Һәм без адреслар эзләдек,
йөрәкне тота-тота...
Менә сиңа ак болыттан
көтмәгән кара яңгыр!..
Хисләрне истән исертеп,
күңелдә дөнья янды...

Хәтергә килә тордылар
абзыйның күп хәлләре.
Алар да көйри башлады
күзләргә төтен бәреп.
Әнә ике җиңги яна:
тән биреп тилерткәне,
соңгы чорын тәмуг итеп,
шул утларга керткәне...
Әнә икенчесе яна —
аңа бала тапканы —
күз бозларын яра-вата,
соңлап чәчәк атканы,
абзыйга да, улына да
бер бәхет булырдае,
юкса Ходай биргән иде,
биргән иде бит җаен...
Яна абзыйның малае,
оныгы һәм килене...
Ә җандагы утлы суык
кимеми дә кимеми...
Чөнки эчтә янган утлар
җылытмыйлар икән ич,
чөнки эчтәге ялкында
пыскый икән үкенеч...
Бит Мәскәүдә, ЦДЛда,
ресторан төтенендә
бәллүр бокаллар чыңлыйдыр,
намуслылыкка өндәп,
абзыйга гомер бәясе
торырлык сабак биргән
теге «дуслар» утырадыр,
бар халыкларны тиргәп!..
Алар янмый!.. Без янабыз
үкенечтән буылып...
Без янабыз... Абзый кала
җил тузгыткан көл булып...

Җирдәге иң авыр гөрзи,
үзем беләм, әләктер!..
Әләк аркасында миңа
газап шактый эләкте.
Ник дөреслек ышандырмый,
әләк ник ышандыра?..
Дөреслек — эчтә, эндәшми,
әләк — тышта, кычкыра...
Ә бездә кычкырган хаклы!..

Ә өлгере — бигрәк тә!..
Дөнья безне уздырыштан
әләкләргә өйрәтә...
Әләкчеләр сирәк яна...
Ә әләк корбаннары...
Аларны да ярлыкыйлар,
беравыктан... аннары...

**22**

Мильон ел кояш күрмәгән
балчык та якты күрде —
абзыйның якты җәсәде
Буа куенына керде...
Чит якта туып, шул җиргә
койса да хезмәт тирен,
үз татарын кабул итә
ата-бабасы җире,
чөнки ул һәрбер теренең
туфрак чагын хәтерли...
Шуңа кабер буласы җир
һәр терегә кадерле...
Абзыйга да бик кадерле
иде Буа яклары.
Зөя агымына каршы
аның йөзгән чаклары
күз алдына бик еш килә:
чәчрәтеп көри иде...
Аннары «Җиңдем бит!» диеп,
кәпрәеп йөри иде...
...Бер йомарлам балчык алып,
җылы сеңдереп учтан,
тирән кабергә ыргыттым:
тынычлан, җан, тынычлан —
без монда, өстә калабыз,
Җир безне таный торсын,
кояш тирәли әйләнеп,
елларны саный торсын.
Әлмәт кода-кодагыйның
күз нуры юеш, сүрән —
уллары хатирәсе дә,
күрәсең, ята үрдә:
— Уйнарга да өлгермәдек
без кодалык уенын, —
диеп кодагый иренең
иңсәсенә сыенды...
Монда телгә алынмаган
дус-ишләр һәм туганнар
бөрешеп кечерәйгәннәр,
әйтерсең лә туңалар,
сары балчыкка ябышып,
өскә чыккан суыктан...
— Артык иртә...
— Йөрәге бит...
— Юк, заман сугып еккан...
— Үзбәкләр кысканнар икән...
— Үлем бай ул сәбәпкә...
— Хатыны, ди...
— Юк, партбилет...

— Чыдамаган әләккә...

Зират өстендә кешеләр
ни генә пышылдашмый!..
Үлгәч, кеше әнә шулай
үзгә гомерен башлый
дусларының хәтерендә,
дошманнар гайбәтендә...
Ләкин ишетми сүзләрнең
кәен дә, әйбәтен дә...

...Җиңги улы җилкәсенә
баш терәп тып-тын тора...
— Бәхет таптым, дип уйладым...
— Бәлки... тапкансыңдыр да...
— Югалтмам, диеп ышандым...
— Бәлки... югалтмассың да, —
диеп пышылдады егет,
үзен юаткан сыман...

Менә шулай, көтмәгәндә,
абзый үлде дә китте —
романымны без күнеккән
җайлы финалсыз итте.
Ә үлеменең сәбәбе —
йөрәге калган туктап.
Медицинага ышансак,
бик көчле инфаркт суккан.
Ә улының сөйләвенчә:
Ташкенттагы җиңгәбез
улына абзый алдында
әйткән көтелмәгән сүз:
— Бәлки, сине тудыргандыр
әнә шул чулак хатын —
син төерләнгән көннәрдә
ул бер курортта ятты,
ләкин эти дигән кешең
ул чак Ташкентта иде...
Тудырган хатынны таптың,
атаңны да тап инде...
Ишеткәчтен бу сүзләрне
абзый агарып каткан...
— Улым! Ялган бу!..— дигән дә,
тирән комага баткан,
һәм инде чыга алмаган,
булышса да докторлар...
Ә җиңгәбез «Кылана!» дип,
ерактан карап торган...
«Ни булды арагызда?» дип
аңлатуын үтенгән.
Җиңги аңа җавап биргән,
сүзен савып үтеннән:
— Ул — несчастный неудачник! —
дигән дә чыгып киткән,
улым дигән кешесенә
сүз дә дәшмәгән бүтән.
Аның сәер гадәтләрен
искә алды аптырап —
улы укыган мәктәпкә
бармаган бер тапкыр да...

Бәлки, аның бушагандыр
чак кына бер фазасы —
шуның хәтле чиксез нәфрәт!..
Җитте, килми язасым,
чөнки аңлап бетералмыйм
ул хатынның күңелен —
ул, мөгаен, бозылгандыр
үз агуы түгелеп...
Ул — бер искәрмә генәдер
җәмгыять үсешендә...
Мутантлар туа әхлак һәм
сәясәт кисешендә...
Акыллылар белән бер үк
бизмәнгә менеп басып,
ахмак та билгели икән
замананың асылын!..

Әйе, абзый үлеп китте,
хәлне авырга куеп...
Шундый буламыни инде
заманыбыз герое?!
Юкса трагедия дә,
драма да түгел бу,
гәрчә бераз гына кан да,
күз яше дә түгелде.
Роман персонажлары да
калдылар сибелешеп —
һәрберсенең үз тормышы,
үз максаты, үз эше.
Эш дигәннән, мин беркемне
хезмәттә күрсәтмәдем,
кемнең кайда укыганын,
эшләгәнен әйтмәдем.
Инандым: кеше дөньяга
килә ич яшәр өчен,
тик шуны тәэмин итәм дип,
хезмәткә сала көчен...
Кешене, әлбәттә, бизи
күкләр яулау, җир тишү!..
Ләкин хезмәт — кием генә...
Кешенең җаны — к е ш е !

Сюжет төгәлләнсен өчен
һәр кешенең язмышын
берсе белән берсен бәйләү —
бераз гына ялгышу
түгел микән әдәбият
белемендә? Бу сорау
теориядә, минемчә,
һаман бик кискен тора.
Тормышта бит алай түгел.
Язмышлар, вакыйгалар
үзләренчә иреклеләр,
үзенчә ага алар.
Кемдер яшәп бетергәндә,
кемнәрдер туа гына...
Алма җимеш була алмый
карлыган куагында.
Юкса янәшә яшиләр...
Куналар бер үк кошлар...

өсләреннән бер үк һава,
бер үк в а к ы т шуыша...
Карлыган картайды, диеп
сынып төшми алмагач...
Тукталасылар туктала,
йөрерлеге калмагач...
Һәр нәрсәнең үз гомере,
хәрәкәте, чикләре.
Һәркемнең үз мәшәкате —
гомер буе чүпләрлек.
Тормыш һич тә хаос түгел,
ул — ирекле хәрәкәт.
Ирек максатка буйсына!
Шунда менә бәрәкәт.
Тупламыйм вакыйгаларны,
язмышларны чикләмим —
көче барлар алга китсен,
ватып роман чикләрен.

Персонажларга исемнәр
тагу бик кирәк микән?
Үрнәк булып, алар безне
яшәргә өйрәтми лә...
Андый язмышлы кешеләр
хәзер Россия тулы —
яшиләр үз чорларында
исемсез батыр булып...
Гыйбрәт-нәсихәт көтүче,
роман буйлап йөзгәндә,
үзенә кирәк сабакны
алыр исемсездән дә...
Шуңа күрә дә аларга
исем куярга базмыйм...
Романны да псевдонимсыз,
псевдо-мин булып яздым.

*28 август, 2001 — 28 декабрь, 2002*


Литературно-художественное издание

*Харисов Ренат Магсумович*

**Безымянные**

Роман в стихах

(на татарском языке)

Редакторы *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Ф.Ш.Хәсьянова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.11.2004. Форматы 70г100 1/32. Офсет кәгазе. «Baltica» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,8. Шартлы буяу-оттиск 8,13. Нәшер-хисап табагы 8,73.
Тиражы 2000. Заказ Э-849.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

ААЖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.